وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№7 (228). Июль / Рамазан – 1435

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



2 бит

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨФТИЕНЕҢ УРАЗА БӘЙРӘМЕ БЕЛӘН КОТЛАВЫ



8-9 бит

## РАМАЗАН ЙӨРӘКЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРДЕ



3 бит

## МӨФТИ ХӘЗРӘТ ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ИФТАР КЫЛДЫ




13 бит

## УЛ МИНЕМ ТУРЫДА ИСТӘЛЕК ЯЗАРГА ТИЕШ ИДЕ...

# Татарстан Республикасы мөфтиенең Ураза бәйрәме белән КОТЛАВЫ

***Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!***

***Мөхтәрәм дин кардәшләребез!***

***Барыгызны да чын күңелдән Ураза гаете белән котлыйм!***



Мөбарәк бәйрәмебездә барча дөнья мөселманнарын берләштергән Раббыбызга мактауларыбыз һәм сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә, һәм аның сахәбәләренә чиксез салаватшәрифләребез булса иде!

Рамазан - мәрхәмәт, изгелек һәм ураза гыйбадәте ае. Рамазан - бәндәләрне тугры юлга юнәлткән Коръән Кәрим иңдерелгән ай. Барлык көннәрдән кадерле Кадер кичәсе дә - бу айда. Коръәндә болар хакында ачык язылган: "Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә, шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын. Хаста булганнар яки сәфәрдәгеләр (тотылмаган көннәре хисабынча) башка көннәрне ураза тотар. Аллаһ сезгә җиңеллек тели, кыенлык теләми. Санаулы (ураза) көннәрен тәмам итеп, сезгә тугры юл күрсәткәне өчен, Аллаһны олылагыз, бәлки сез шөкер итәрсез?" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 185 нче аять).

Рамазан аенда ураза тотуның мөһимлеге турында Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе булса иде) хәдисендә болай диелә: "Ураза тотучының ике шатлыгы булыр: ифтар (авыз ачу) шатлыгы һәм Аллаһы Тәгалә белән очрашу шатлыгы". Тагын бер хәдистә: "Рамазан аенда иман белән һәм савапка ирешүгә өмет баглап ураза тоткан кешенең элеккеге барча гөнаһлары да ярлыканыр", - диелгән.

Барча мөселманнар мөбарәк Рамазан ае дәвамында тәравих намазларында: "Ий Раббыбыз, Сиңа гына сыенабыз, коллык итәбез, Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Барча кардәшләребезне тугры юлга күндер", - дип ялварып, Раббыбызга сыенды һәм илебезгә, якыннарыбызга ямьле, бәрәкәтле көннәр теләде.

Аллага шөкер, бу мөбарәк айны ниятләребезне яхшыга юнәлтеп, начарлыктан качарга, телләребезне гайбәттән, ялганнан тыярга, тәнебезне дә, күңелебезне дә хәрәмнән арындырырга тырыштык.

Аллаһы сүбхәәнәһү вә Тәгалә тоткан уразаларыбызны, кылган гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итеп, Үзенең рәхимшәфкатеннән ташламаса иде. Аллаһ исемен зикер итеп, күңелләребез белән бары Коръәнгә, иманга ашкынып үткән рамазан ае савапларына ирешергә язсын. Нәфесебездән өстен калып, яхшы гамәлләр генә кылып, киләсе рамазан айларын да исәнсау, бердәм булып каршы алырга насыйп итсә иде!

***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

## ГАЕТ КӨННӘРЕ БИЛГЕЛЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов быел республикада Ураза һәм Корбан гаетләрен бәйрәм итү көннәре турындагы Указга кул куйды. "ТРда бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталар турында"гы ТР Законының 1 нче маддәсе нигезендә 2014 нче елның 28 нче июле Ураза гаетен бәйрәм итү көне буларак билгеләнгән; 4 нче октябрь - Корбан гаете.

***Указ ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан 2014 нче елның 1 нче июлендә имзаланган.***

## МӨСЕЛМАН ОНЛАЙН-ФЕСТИВАЛЕНӘ ТЕРКӘЛҮ БАШЛАНДЫ

1-15 нче август көннәрендә Россия Мөселман яшьләре берлеге тарафыннан беренче мәртәбә Мөселман онлайн-фестивале оештырыла. Анда катнашырга меңнән артык кеше теләк белдерде инде. Фестивальдә катнашу өчен online-islam.ru сайтында теркәлергә мөмкин.




## "БЕРГӘЛӘП, УРТАК ЭШ БАШКАРАБЫЗ"

**Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгында 3 дәрәҗәле урта мөселман һөнәри белем бирү стандартлары хакында сөйләшү булды. Уку-укыту стандартлары ТР МДНнең уку-укыту методик берлеге тарафыннан әзерләнде. Эшлекле сөйләшүдә ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, Россия Ислам институты ректоры, уку-укыту методик берлеге җитәкчесе Рәфыйк Мөхәммәтшин, Диния нәзарәтнең уку-укыту бүлеге җитәкчесе Руслан хәзрәт Таһиров һәм башкалар катнашты.**

Рәфыйк Мөхәммәтшин сөйләшүдә катнашучыларны уку-укыту методик берлеге эшчәнлеге белән таныштырды. Әлеге берлекнең дини мәгариф өлкәсен камилләштерү максатыннан оештырылуы хакында әйтте. Мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров министрга мөфтинең хатын һәм уку-укыту стандартлары проектларын тапшырды. Стандартлар түбәндәге юнәлешләрдә эшләнгән: "Ислам фәннәре һәм тәрбия. Башлангыч әзерлек", "Ислам фәннәре һәм тәрбия, гарәп теле. Төп әзерлек", "Ислам фәннәре һәм тәрбия, гарәп теле. Югары әзерлек". Рөстәм хәзрәт мондый төр стандартларның Россиядә беренче тапкыр эшләнүе һәм гамәлгә кертелүе хакында сөйләп, министрдан стандартларның Мәгариф турындагы законга туры килүенә кагылышлы экспертиза үткәрүләрен сорады. Министр әлеге экспертизаның озакка сузмый үткәреләчәген әйтте. "Без бергәләп, бер юнәлештә уртак эш башкарабыз", - дип ассызыклады ул.

## АПАНАЙ МӘЧЕТЕ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНӘ ТАПШЫРЫЛДЫ

**Дәүләт милке белән идарә итү буенча федераль агентлык Апанай мәчете бинасын федераль милектән Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте карамагына рәсми төстә тапшырды. Чарада катнашкан Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин: "Шулай итеп, мөселманнарның инкыйлабка кадәр төзелгән күчемсез вәкыф милкен кабат кайтару процессы башланды. Хәзер Апанай мәчете юридик яктан нәзарәтнеке", - дип аңлатып үтте.**



Апанай мәчетендә үткән рәсми чарада шулай ук Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Дәүләт милке белән идарә итү буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары Игорь Бабушкин, мәчетнең имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров, мәхәллә халкы катнашты.

Казанның Каюм Насыйри урамындагы Апанай мәчете төзелгәнгә ике гасырдан артык, ул 1768 нче елда салына. Иске татар бистәсенең күрке булган иман йорты 1930 нчы елда ябыла. Еллар узу белән аның манарасы, гөмбәзе җимерелә. 1995 нче елда тарихи мәчет ТР Министрлар Кабинетының 660 нчы карары нигезендә мөселман мәхәлләсенә тапшырыла. Бинаны төзекләндерү эшләре башлана.

Дистә еллар дәвамында мәчет Татарстан җитәкчелеге, тарихи корылмаларны саклау буенча төрле федераль программалар, аерым кешеләрнең хәйрия ярдәме белән төзекләндерелде. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, Президент Рөстәм Миңнеханов булышлыгында, мәчетнең имам-хатыйбы, танылган дин әһеле, мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якупов тырышлыгы белән төзекләндерелгән мәчет 2011 нче елның декабрь аенда кабат ишекләрен ачты. Төзекләндерү эшләре 52 миллион сумга төште.

Мәчетнең бүгенге имамхатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров сүзләренә караганда, Вәлиулла хәзрәт башлаган дини эшчәнлек дәвам иттерелә. Биредә танылган дин әһелләре вәгазьләр укый, мәктәп яшендәгеләр өчен конкурслар үткәрелә, лагерьлар оештырыла.

# МӨФТИ ХӘЗРӘТ ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ИФТАР КЫЛДЫ



**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте дин темасына язучы 50 ләп журналистны ифтарга җыйды. Мәҗлестә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, "Татмедиа" агентлыгы җитәкчесе урынбасары Илдар Сәгъдәтшин катнашты. Әлеге дини мәҗлес ислам кыйммәтләрен халыкка җиткерүгә күп өлеш керткән каләм ияләренә рәхмәт әйтү, үзләре дә ураза тоткан, намаз укыган журналистларга мөбарәк рамазан аенда бер җыелып дин хакында сөйләшергә мөмкинлек тудыру ниятеннән оештырылды. Ифтар мәҗлесенә килгәннәр бергәләп намаз укыдылар, дога кылдылар, аннары үз фикерләрен һәм сорауларын җиткерделәр.**

Бүгенге көндә татар матбугатында ислам кыйммәтләрен җиткерүче даими сәхифәләр дөнья күреп килә. Дин темасын яктыртуда махсуслашкан журналистларыбыз да бар. "Динебез хакында без, имамнар, мөнбәрдән сөйлибез, нәсыйхәтлибез. Ә сез, газеталарга язып, сюжетлар ясап, шушы нәсыйхәтләрне җиткерергә, безгә дини эшчәнлекне алып барырга ярдәм итәсез", - диде алар белән аралашканда мөфти Камил хәзрәт. Шулай ук ул ураза тоту, Коръән укуның саваплары хакында да җиткерде. Үзе дә бар ихласын биреп матур аһәңле тавышы белән Коръән укып, мәҗлескә җыелганнарның калебләренә нур өстәде ул. Дога кылып, Аллаһы Тәгаләдән барчабызга иминлек, бәрәкәт, иман ныклыгы, ярдәм сорады. Аннары аның урынбасарлары - Рөстәм хәзрәт Батров һәм Рөстәм хәзрәт Хәйруллин үзләренең үгет-нәсыйхәтләрен җиткерделәр.

Мөхтәрәм дин әһелләренең сүзләренә журналистлар да кушылды.

Әйтик, "Манзара" ("Татарстан - Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе) тапшыруын алып баручы танылган журналист Илдар Кыямов нәзарәт тарафыннан рамазан аена махсус әзерләнгән социаль роликларның мөһимлеген билгеләп үтте. Әлеге роликлар мәрхәмәтле булырга чакыра, рамазанны изгелек төшенчәсе аша аңларга булыша. Илдар әфәнде узган ел уздырылган хәйрия телемарафонын искә төшереп, бу эштә телеканал хезмәткәрләренең зур тырышлык куюлары хакында да әйтте.

Өлкән яшьтәге каләм ияләре Әлмира апа Әдиатуллина һәм Вәсилә апа Рәхимовалар шәхсән мөфтигә һәм нәзарәткә республикабызда алып барылган уңай дини эшчәнлек өчен рәхмәтләрен җиткерделәр. "Бүгенге көндә динебез үсәр өчен һәм исламга килер өчен бар мөмкинлекләр дә бар", - диделәр алар. Әлбәттә инде, яшьләр колагына кереп калырлык итеп, үзләренең башларыннан үткәннәрне дә сөйләп уздылар.

Журналист Искәндәр Сиражи исә мәҗлескә "күчтәнәч" белән килгән иде. Ул яңа гына табадан төшкән "Сиражи сүзе" газетасын таратты. "Нәсыйхәт" ("Татарстан - Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе) тапшыруының автор һәм алып баручысы Ләйсирә Фазлыева исә хәзрәтләргә рәхмәт әйтеп, үзенең сорауларын да юллады. "Фитыр сәдакасы бирү бик тә саваплы гамәл. Аны нәкъ менә мохтаҗ кешеләргә бирәсе килә. Фитыр сәдакасына мохтаҗ булганнарны каян табарга? Хәзрәтләр, сез аларны ничек табасыз?" - диде ул. Әлеге сорауга мөфти Камил хәзрәт: "Мәчетләргә фитыр сәдакасы бирү тартмасы куела. Мохтаҗларга ул шуннан алып бирелә. Аннары мәчетләрдә эшләүчеләр шәһәр хакимиятенә, район социаль яклау бүлекләренә чыгалар. Шулар аркылы мохтаҗларны табабыз", - дип җавап бирде.

Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, әлеге теманы дәвам итеп, мәдрәсәләрдә белем алучы шәкертләр дә, авылларда эшләүче кайбер имамнар да ярдәмгә мохтаҗ икәнне әйтте. "Авыл имамнарына, бигрәк тә читтән килгән яшь имамнарга яшәргә урын, ашарга ризык, кияенергә кием кирәк. Әмма халык аларны фәрештә дип уйлый кебек. Фәрештәләргә генә йокларга да, ашарга да кирәкми", - диде ул.

Журналистларның күркәм ифтар мәҗлесе Казанның Петербург урамында берничә атна элек кенә ачылган "Хурма" ресторанында узды. Ресторан хуҗалары һәркемне ачык йөз белән каршы алдылар, тәмледән-тәмле ризыклар белән сыйладылар.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА***

# МОХТАҖЛАР ӨЧЕН "РАМАЗАН ХӘЗИНӘСЕ"




**Рамазан аенда Казанның Тынычлык мәчете ишегалдында мохтаҗлар өчен ризыклар тутырылган суыткыч куелды. "Рамазан хәзинәсе" дип аталган суыткыч даими рәвештә ипи, тәм-томнар, төрле ярмалар белән тулыландырылып тора. Биредә теләгән һәркем мохтаҗлар өчен сәдака итеп ризыклар калдырып китә ала. Мохтаҗларга һәм картларга ярдәм итү йөзеннән мондый төр акция беренче мәртәбә уздырыла.**

"Пәйгамбәребез бик юмарт булган. Рамазан аенда бигрәк тә мохтаҗларның һәм тирә-юньдәгеләрнең күңелен күргән, аларга ярдәм иткән. "Рамазан хәзинәсе" юмарт булырга һәм миһербанлылык күрсәтергә этәрә торган бер чара. Суыткычка күпме ризык калдырып китүең мөһим түгел, чөнки кечкенә сәдака бирү дә үзе бер изгелек", - ди Камил хәзрәт Сәмигуллин, акциягә карата фикерләре белән уртаклашып.

# "ТАТЛЫ РАМАЗАН" АКЦИЯСЕ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм социаль ярдәм күрсәтү бүлеге хезмәткәрләре "Зәкят" хәйрия фонды белән берлектә "Татлы рамазан" акциясе уздырды. Мөселманнар Казанның Бауман урамына чыгып, халыкка Изге рамазан аеның фазыйләтләре, ураза тотуның әһәмияте турында сөйләделәр. Моннан тыш акциядә катнашучылар рамазан аенда игелекле гамәлләр кылырга өндәделәр һәм халыкка күчтәнәч итеп хөрмә җимеше өләштеләр. Әлеге акция казанлылар һәм башкалабыз кунаклары күңеленә хуш килде, алар күчтәнәч өчен дә, файдалы мәгълүмат өчен дә рәхмәтләрен җиткерделәр.**

Диния нәзарәте хезмәткәрләре көн саен игелекле гамәлләр кылырга тырыша, мохтаҗларга, инвалидларга, ятимнәргә һәм аз керемле гаиләләргә кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтә.




# БИЗНЕСМЕН БУЛАСЫҢ КИЛӘМЕ?

***Россия мөселман яшьләре берлеге Яңа инновацион-интеллектуаль технологияләр компаниясе белән берлектә тиңе булмаган "70 көн эчендә уңышлы онлайн-бизнес" воркшоп (workshop) коучинг оештыра.***

Коучинг кысаларында яшь мөселманнар AsianDreams ("Сны Азии") проекты үрнәгендә шәригать законнарына каршы килмәгән интернет сервислар һәм ресурслар әзерләп, эшләтеп җибәрергә өйрәнәчәкләр.



Уку барышында мөселман яшьләре Азамат Ушанов (e-mail маркетинг), Олесь Тимофеев (беренче Россия һәм БДБ интернет-эшкуарлар берлегенә нигез салучы), Алекс Яновски (АКШ мультимиллионеры, шәхси бизнес мәктәбе хуҗасы), Эльдар Гузаиров (YouTube ны Россиядә җәелдерүче белгеч), Айнур Абдулнасыйров (LinguaLeo сервисына нигез салучы), Олег Тиньков (ТКС банкына нигез салучы), Рөстәм Нәҗипов ("ТурбоТрафик", "Онлайн-Университет.ру" проектлары авторы) кебек мәшһүр эшмәкәрләрнең иң алдынгы тәҗрибәләрен өйрәнәчәк.

"Без коучингка 5 кенә кешене сайлап алабыз, алардан проектлар әзерләүче интернет белгечләр ясаячакбыз. 70 көн эчендә без аларга шундый гыйлем һәм тәҗрибә бирергә ниятлибез, нәтиҗәдә бу яшь белгечләр AsianDreams ("Сны Азии") проекты кысаларында безнең партнерларыбыз булып эшли алачак", - ди Мөселман яшьләре берлеге җитәкчесе Марсель Сабиров.

Коучингны оештыручылар onlineislam.ru@gmail.com адресы буенча яшьләрдән заявкалар көтә. Хатта ни өчен әлеге проектта катнашырга теләвегезне, эш урыныгызны һәм контактларыгызны күрсәтергә кирәк. Укулар Диния нәзарәте бинасында алып барыла.

## *Намаз вакытлары рус телендә*

Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хузур" нәшрият йорты белгечләре тарафыннан мобиль җайланмалар өчен "Намаз вакытлары"ның русча варианты эшләнде. Татарстан өчен генә төзелгән "Намаз вакытлары" программасы Android һәм IOS өчен яраклаштырылган. Android һәм IOS сылтамаларына кереп, аны үз телефоныңа күчерергә мөмкин. Программада намазның нәрсә икәне аңлатылган, гыйбадәт кылу вакытлары күрсәтелгән, компасы да бар.




***Язмалар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (dumrt.ru) алынды***

# ИСЛАМ – ГАКЫЛ ДИНЕ

**Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның Хаттат Хафиз Йосыф Таваслының "Рамазан аенда 30 вәгазь" китабы буенча сабаклары**

Кардәшләрем! Безнең динебез вәгазьләргә нигезләнә. Дин үгет-нәсыйхәт белән ныгый. Нык дин булган җирләр - нәсыйхәтләр, вәгазьләр белән тулы җирләр. Бу хакыйкатьне Аллаһыбыз Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) болай аңлата:

*"Дин - үгет-нәсыйхәт ул". Аллаһы Тәгалә Илчесе (с.г.в.) бу сүзләрне өч тапкыр кабатлый: "Дин - үгет-нәсыйхәт ул. Дин - үгет-нәсыйхәт ул. Дин - үгет-нәсыйхәт ул".*

Ислам - бөтен кешелек дине. Ислам дине кеше бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешсен өчен иңдерелгән. Түбәндә китерелгән аятьтә Аллаһы Тәгалә кешенең Аңа гыйбадәт кылу өчен яралтылганын аңлата:

**"Мин кешеләрне һәм җеннәрне бары тик Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен яралттым"** ***("Зарият (Таратучы)" сүрәсе, 56 нчы аять).***

Шулай булгач, кеше яралтылуның мәгънәсе - аның Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышануында һәм Аңа гыйбадәт кылуында. Кеше гыйбадәт кылу өчен яралтылган. Гыйбадәт кылу кешенең бурычы булып тора. Кеше гыйбадәт кылган очракта гына кеше булып кала. Әгәр дә үз бурычын үтәми икән, ул үзенең төп кыйммәтен югалта һәм кеше булу бәхетеннән мәхрүм ителә.

Аллаһы Тәгалә һәр яралтылганга үз вазыйфасын йөкли. Мәсәлән, көтүче эте көтүне, хайваннарны һәм хуҗасының өен саклый. Хуҗасы кич белән өенә кайткач, ул аны танымыйча өрә башласа да, хуҗасы чакыргач, шунда ук янына йөгереп килә, аның аяк астына килеп ята, койрыгын болгый. Үзенчә хуҗасыннан гафу үтенә: "Хуҗам, гафу ит мине. Мин сине танымадым, өебезгә һәм мал-туарларыбыз янына чит кеше якынлашты дип уйладым. Минем бурычым - саклау, шуңа күрә, бурычымны үтәр өчен, мин өрә башладым". Эт хуҗасына әнә шуны җиткерергә тырыша кебек.

Әйе, эт, хайван булуына карамастан, үз бурычын төгәл үти, ә кеше үз бурычын үтәми - гыйбадәт кылмый. Үзен кеше дип йөрткән җан иясенә болай әшләү килешәме? Кешенең кыйммәте аның Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышануында. Әгәр дә кеше моны төшенмәсә, аны кеше дип атап буламы? Әлбәттә, юк. Барлык җан ияләре дә үз бурычларын үтиләр. Үгез җир сөрә, ишәк йөк ташый, сыер сөт бирә. Алар барысы да бары тик кешегә файда китерер өчен яралтылган. Ә кеше исә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга битараф карый.

Бервакыт бер кеше сукырая һәм табиб янына бара. Табиб аны карый да күзлек бирә. Бу кеше шатлыгыннан табибка җанын бирергә әзер булуын әйтә. Карагыз әле: нинди юмарт кеше! Ике пыяла һәм каймадан торган күзлек биргән табибка үзенең җанын бирергә әзер, ә аңа күзләр бүләк итүчегә биш-ун минут вакыт таба алмый. Күзләре булмаса, аңа бернинди табиб күзлекләре дә булыша алмавы турында уйлап та карамый. Димәк, кирәк чагында ул үз акылын куллана белми.

Бу гүзәл принципны сине юктан бар иткән, сиңа күз, колак, куллар, аяклар биргән, сине иң яхшы сурәттә ишетү һәм күрү сәләтләре белән яраткан, сиңа буй-сын биргән, яшәр өчен матди байлык белән тәэмин иткән, сине үстерүче, сине акыллы һәм фикер йөртүче итеп яралткан Аллаһы Тәгаләгә карата куллансаң икән! Аллаһы Тәгалә сиңа биш вакыт намаз кылырга боера, син аны кылсаң икән! Аллаһы Тәгалә сиңа елга бер тапкыр Рамазан аенда ураза тотарга куша, син ураза тотсаң икән! Аллаһы Тәгаләне "Лә иләәһә илләллаһ, Мөхәммәдүррасүлуллаһ!" дип кабатлап, исеңә төшереп торсаң икән!

Чын мөэмин мөселман беркайчан да алданмас. Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) болай дигән:

*"Аллаһы Тәгаләгә ихлас ышанучы кеше карашынан куркыгыз, чөнки ул Аллаһы Тәгалә нуры белән карый".* Икенче хәдистә Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) болай ди:

*"Мөселман кешене бер өннән ике тапкыр тешләмәячәкләр (ягъни, ул ике тапкыр алданмас)".* Чын мөселман ялганламый һәм ялганга бирешми. Чөнки мөселманнарга башка мөселманнар турында бары тик яхшы уйлар гына уйларга кушылган. Мөселман кешегә башка мөселманнарны яхшы дип уйларга яки яхшы кешеләр булачак дип уйларга кирәк. Начар холыклы кеше белән очрашса һәм аның тарафыннан алданганын белсә, мондый кеше белән икенче тапкыр сак булырга тиеш. Мөселман кеше начар холыклы кешедән икенче тапкыр алданмас, үзенә тагын бер тапкыр зыян салырга рөхсәт итмәс. Әгәр дә инде икенче тапкыр алданса, бу аның иманының камиллегендә шик тудыра. Шуңа күрә ихлас күңелдән ышанган мөселман үзе алдамаган кебек, үзен икенче тапкыр алдауны булдырмас!.. Кайвакыт, мөселманнарны алар башка кешеләргә карата яхшы фикердә булулары аркасында алдыйлар, дигән сүзләр ишетергә туры килә. Бу - ялгыш фикер. Игелекле, саф, йөрәгендә иман нуры булган мөселман алданган була аламыни? Ислам ахмаклар өчен, ахмаклар динемени? Әлбәттә, юк! Ислам - гакыл дине. Ислам акыллы кешеләргә мөрәҗәгать итә. Ислам акыллы кешеләргә бурычлар йөкли.

Кардәшләрем! Игътибар белән карасак, ислам дине

> ***Сәхабәләре Пәйгамбәребездән (с.г.в.): "И, Аллаһы Тәгалә Илчесе! Чын мөселман дип кемне атарга була? Чын мөселман сыйфатлары турында сөйләмәссең микән?"- дип сораганнар. Бу сорауларга Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дип җавап кайтарган: "Чын мөселман - куллары һәм теле белән башка кешеләргә зыян китермәгән һәм кайгыга салмаган кеше".***

канунннары буенча яшәгән мөселманнарның тыныч күңел белән, беркемгә дә зыян китермичә һәм беркемнән дә зыян иттермичә яшәүләрен күрербез. Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) болай ди:

*"Теленнән һәм кулларыннан башка мөселманнар зыян күрмәгән кеше генә - чын мөселман".*

Сәхабәләре Пәйгамбәребездән (салләллаһу галәйһи вәсәлләм): "И, Аллаһы Тәгалә Илчесе! Чын мөселман дип кемне атарга була? Чын мөселман сыйфатлары турында сөйләмәссең микән?"- дип сораганнар. Бу сорауларга Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) болай дип җавап кайтарган: "Чын мөселман - куллары һәм теле белән башка кешеләргә зыян китермәгән һәм кайгыга салмаган кеше".

Кардәшләрем, игътибар итегез! Чын мөселманны тасвирлаганда Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) аны намаз укучы, ураза тотучы һәм зәкят түләүче кеше дип, әйтмәгән. Намаз - диннең таянычы һәм диварлары. Ул диварларны матур булсын өчен штукатурлыйлар һәм буяу белән буйыйлар. Штукатурка һәм буяусыз бина ахырына кадәр төзелеп бетмәгән, матур булмау сәбәпле кеше игътибарын үзенә җәлеп итмәгән кебек, намаз укучы һәм ураза тотучы, ләкин башкаларга зыян салучы кеше чын мөселман булып исәпләнә алмый. Һәр нәрсәне камил итәргә була. Пәйгамбәребезгә биргән сораугa да камил мөэмин мөселман турында мәгънә салынган.

Намаз укучы һәм ураза тотучы кеше башка мөселманнарга зыян китерсә һәм җаннарын газапка салса да барыбер мөселман булып исәпләнә, ләкин камил, яхшы һәм ачык күңелле мөселман булмый. Башка мөселманнарга зыян салучы мондый кеше тупас һәм оятсыз мөселман була. Андый мөселманны Аллаһы Тәгалә, Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) һәм башка мөселманнар яратмаячак. Үз динен яраткан, акылы булган мөселман Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) хәдисендәге күрсәтмәләргә нигезләнеп эш итәчәк, беркемгә дә зарар китермәскә тырышачак.

Аллаһы Тәгалә юлы - Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) юлы, Җәннәт юлы, бер сүз белән әйткәндә, кешелеклелек юлы ул.

Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) болай дигән: "И, мөселманнар! Мөселман кардәше өчен үзенә яратканны яратмыйча, арагыздан берегез дә ышанучы булмаячак". Җир йөзендә, акылы була торып, үзенә начарны теләгән кеше юк. Шулай булгач, үзенә яхшылыкны теләгән мөселман башкаларга да яхшылык теләргә тиеш. Кешеләр аңа булышалар, хөрмәт күрсәтәләр, аның ярдәм сорап мөрәҗәгать итүләренә җавап бирәләр, ә ул беркемгә дә булышмый, беркемгә дә игелек кылмый! Болай эшләргә ярамый! Ислам динендә бу юк.

Үзен һәм динен яраткан кеше, үзенә теләгән игелекне башка кешеләргә дә теләячәк, хәленнән килгәнчә башка кешеләргә булышачак. Бу кешелеклелек һәм дин юлы була да инде. Җәннәт һәм Аллаһы Тәгалә Илчесе (с.г.в.) юлы.

Мөселманнар Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) бу хәдисен тормышка ашырсалар, күңелләре тыныч булачак. Ислам диненең төп максаты - кешеләр тыныч һәм бәхетле булсыннар өчен барлык шартларны тудыру.

Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) болай ди:

*"Башкалардан үрнәк алучы кеше - бәхетле (акыллы) кеше. Бәхетсез (акылсыз) кеше - үзенең начар хәле белән башкаларга сабак бирүче кеше".*

Мөхтәрәм мөселманнар! Бу хәдиснең мәгънәсе шулкадәр тирән ки, кеше аның тәфсирен сәгатьләр буе тыңлый ала. Акылы булган мөселман яхшы кешеләрдән үрнәк ала һәм үз тормышында кулланырга тырыша. Шулай ук акыллы мөселман башка кешенең начар гамәленнән сабак ала һәм үзен андыйдан сакларга тырыша. Начар кешеләрнең тискәре гамәлләре нәтиҗәләреннән ул үзен саклый. Башкача әйткәндә, акылы булган мөселман үрнәкне һәм сабакларны башка кешеләрдән ала. Акылсыз һәм бәхетсез кеше барлык начар гамәлләрне үзе кыла, ә соңыннан, тискәре нәтиҗәләрен күргәч, кайгыга бата. Аның күңеленнән тынычлык кача, гаиләсе, мал-мөлкәте таркала. Шул рәвешле ул башкалар өчен сабак булып тора. Бары тик дин юлы белән генә тормыштан сабаклар алып була. Йөрәгендә иман булган кеше үрнәк һәм сабак алудан бәхет таба. Йөрәкләре иман тулы кешеләр сабый бала гамәлләреннән дә үрнәк һәм сабак ала.

Мөхтәрәм Гомәр (радыйаллаһу ганһү) мәчеткә иртә килә торган була. Бервакыт ул кечкенә баланың иртән иртүк мәчеткә йөгерүен күрә. Мөхтәрәм Гомәр (радыйаллаһу ганһү) бу баладан аның мәчеткә йөгереп баруының сәбәбен сорый. Бала болай дип җавап кайтара:

- Мин намазга ашыгам. Намаз вакыты якыная, ә мин тәһарәт алмаган. Азан әйтелгәнче тәһарәт алып өлгерәсем килә.

- Син бит әле кечкенә, сиңа намаз уку фарыз түгел, - ди аңа мөхтәрәм Гомәр (радыйаллаһу ганһү) .

- Намаз кылуда яшь аермасы бармыни? Кичә үлгән бала миннән кечерәк иде, - дип җавап бирә аңа бала.

Баланың бу сүзләре мөхтәрәм Гомәрнең (радыйаллаһу ганһү) күңеленә үтеп керә, ул елый башлый, хәтта күз яшьләреннән кулмәге юешләнә. Шуннан соң ул болай ди:

- Я Аллаһ! Бу бала нинди яхшы һәм акыллы!

Кардәшләрем! Сабак алу - мөселманнарның бурычы. Аллаһы Тәгалә Илчесенең (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) шәкерте булган мөхтәрәм Гомәр (радыйаллаһу ганһү) сабый бала гамәлен күреп елый.

Аллаһы Тәгалә безгә Үзенең чиксез нигъмәтләреннән өлеш чыгарсын иде! Барыбызга да башкаларга яхшы үрнәк булырлык дәрес һәм матур тормыш бүләк итсен иде! Кешеләргә начар үрнәк бирүдән сакласын иде!

***Татарстан Республикасы мөфтие***
***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

# ИЗГЕ БӘЙРӘМЕБЕЗ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

**Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, шул галәмнәрне тәрбия кылып һәм Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләп торучы Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәналарыбыз (мактауларыбыз), олуглауларыбыз булса иде. Безне хак юлга күндерүче, барчаларыбызга иң күркәм үрнәк булучы, сөекле, нурлы Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәсәлләмгә, барлык сахабәләренә күңелләребезнең төрләреннән чыккан сәламнәребез, салават-шәрифләребез һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.**

Рамазан аеның дәрәҗәсе турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләм болай дигән: *"Рамазан ае - айларның хуҗасыдыр" (Бәйһәкый).* Рамазан ае керсә, Гомәр радыйаллаһу ганһү: "Хуш килдең безне пакьләүче", - дип әйтә торган булган. Рамазан аенда ураза тоту ислам дине баганаларының берсе булып тора. Шуңа күрә, изге рамазан ае - барлык айларның солтаны. Рамазан аеның башка айлардан өстенлегенең берничә сәбәбе бар:

1. Бу айда аять-аять булып, аерым сүрәләр булып җир йөзенә Коръән иңә башлаган.
2. Бу айда Кадер кичәсе бар. Кадер кичендә Ләүхелмәхфуздән күк йөзенә Бәйтелгыйззәгә Коръән индерелә. Ул кичәне Аллаһы Тәгалә: *"Мең айдан да хәерлерәк"*, - ди.
3. Иң төп сәбәбе - Аллаһы Тәгалә Үзенең мәрхәмәте белән елның бер аен ахирәттә мәңгелек бәхеткә ирешү өчен билгеле бер вакыт итеп кылды. Үзләренә бирелгән мөмкинлекне дөрес аңлаган мөселманнар бу айда тормышларын Коръәнгә һәм Сөннәткә генә таянып алып барырга тырыша һәм шул рәвешчә Рамазан гаетенең иртәсенә кадәр олуг әҗер-савапларга һәм гөнаһларының кичерелүенә ирешә.

Барлык айларның хуҗасы булган рамазан ае - бик бәрәкәтле булган гыйбадәт ае. Бу айда күк капкалары ачылып, бөтен галәмгә Аллаһның рәхмәте тарала. Бу айда кылынган гыйбадәтләргә әҗер-савап башка айларга карагандa күбрәк бирелә һәм адәм баласының гөнаһлары кичерелә. Шуңа күрә без бу айда дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче миллионлаган дин кардәшләребез кебек үк ураза тоттык, тәравих намазлары укыдык, изге гамәлләрне күбрәк кылырга тырыштык, күңелләребезне тынычландырдык, ихласлыкларыбызны ныгыттык. Аллаһы сүбхәәнәһү вә Тәгалә Коръән Кәримдә болай ди: **"Әй иман китергән кешеләр, сездән алдагы кавемнәргә фарыз булган кебек, сезгә дә ураза фарыз булды, уразаларыгызны тотыгыз, шаять, тәкъвалылардан булырсыз"** ***("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 183 нче аяте).***

Аллаһы Тәгалә үзенең колларына битараф түгел. Ул ай буе ураза тотуны йөкле һәм ураза тотуны безгә җиңеләйтә. Ураза тотучыга җиңеллек булсын өчен аны котыртып торучы шайтаннар богаулана, аның өчен җәннәт ишекләре ачыла һәм җәһәннәм ишекләре ябыла. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләм болай дигән: *"Рамазан ае башланса, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла һәм шайтаннар чылбырлар белән богаулана" (Бохари).*

Ураза тотуның фарызлары булып ашау-эчүдән һәм якынлык кылудан тыелу тора, әмма кеше бу айда шулай ук үзенең бөтен начар гадәтләреннән, гөнаһлардан да тыелырга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләм: *"Кем уразалы була торып та ялган-гайбәттән тукталмаса, аның ач йөргеннән берниндиi дә файда юк"*, - дигән (Ибне Маҗәһ).

Уразаны Аллаһы Тәгалә Үзе өчен кылына торган гамәл дип атый, адәм баласына ураза турында махсус мөрәҗәгать итә һәм аны ураза тотучылар өчен генә бирелә торган махсус әҗер-саваплар белән сөендерә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд, салләллаһу галәйһи вәсәлләм, әйткән: *"Адәм баласының һәр гамәле үзе өчен. һәр изгелеккә ун савап, хәтта ул җиде йөзгә кадәр арттырылыр. Аллаһы Тәгалә әйтте: "Уразадан башка. Чөнки ул Минем өчен һәм аның савабын да Мин Үзем бирермен (ягъни җиде йөздән дә арттырыбрак дигән мәгънәдә). Адәм баласы Минем өчен ризыгын, эчемлеген калдыра, хатыны белән якынлык кылмый. Аллаһы Тәгалә каршысыннан ураза тотучының авызыннан килә торган ис иң яхшы хушбуй исеннән дә яхшырак. Ураза тотучыга ике шатлык: берсе - ифтарда (ягъни авыз ачканда), икенчесе - үзенең Раббысы белән очрашканда" (Мүснәд Әхмәд, Бәйһәкый).*

Шулай ук Рәсүл әкрам, салләллаһу галәйһи вәсәлләм, Аллаһ ризалыгы өчен ихлас күңелләреннән ураза тотучыларны сөендереп: *"Кем бу айда уразаның фарызлыгына ышанып һәм Аллаһның ризалыгын теләгән хәлдә ураза тотса, аның гөнаһлары кичерелер"*, - дигән (Бохари, Мөслим).

Икенче бер хәдис-шәрифтә әйтелгән: *"Җәннәттә бер ишек бар, ул әр-Райян дип атала. Кыямәт көнендә аннан ураза тотучылар гына керер, алардан башка һичкем кермәс. Әйтелер: "Кайда ураза тотучылар?" Алар шул ишеккә агылып торыр. Алардан башка һичкем бу ишектән кермәс. Алар кергәч ишекләр ябылыр, алардан башка бу ишекләрдән беркем дә кермәс" (Бохари).*

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә омтылган мөселман рамазан аенда үзе турында гына түгел, башкалар турында да, дине турында да кайгырта, булган малыннан зәкятен чыгара, гади сәдакалар биреп мохтаҗларның, ятимнәрнең күңелен күрә, ислам дине күтәрелүгә үзенең өлешен кертә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлләмнән: *"Нинди садака өстенрәк?"* - дип сораганнар. Ул: *"Рамазан аенда бирелә торган садака"*, - дигән (Тирмизи).

Садака - динебезнең аерылмас бер өлеше. Ул бирүчене нәфесеннән сакланырга мәҗбүр итә, алучының күңеленә өмет кертә, тормышына ямь бирә, җәмгыятьнең тигез, тыныч үсешен тәэмин итә. Шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд, салләллаһу галәйһи вәсәлләм, булган малын садака итеп таратып бетерергә тырышкан һәм башкаларны да шуңа өнди торган булган. Аның үрнәгендә сахәбәләр дә шулай эшли торган була. Ибне Габбастан риваять кылына: *"Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәлләм кешеләрнең иң юмарты иде. Рамазан аенда исә Җәбраил фәрештә белән очрашканда ул тагын да юмартрак була иде. Җәбраил фәрештә рамазан аеның һәр кичәсендә аның белән очраша һәм алар бергәләшеп Коръән укый иде. Шушы очрашулардан соң, ул үз юлындагы каршылыкларны белми торган бәрәкәтле җилдән дә юмартрак була торган иде".*

Садака бирү - үтәү (башкару) өчен иң җиңеле, ә шайтан аны иң авыры итеп күрсәтә. Шуның өчен дә садака кешенең исламга карашын билгели торган бер күрсәткеч булып тора. Ягъни, кеше садака бирсә, мохтаҗларга, ятимнәргә, авыр хәлдә калучыларга булышса, димәк, ул мөселман һәм ислам диненә ярдәм итүче, әгәр мөмкинлеге була торып та ярдәмен күрсәтмәсә - ул Пәйгамбәребез, салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең, сөннәтеннән читләшүче.

Һиҗри исәп буенча быелгы - 1435 нче елның изге рамазан ае тәмамланып килә. Әмма: "Рамазан ае бетте", - дип, адәм баласы Бөек Раббыбызга гыйбадәтен һәм итагатен ташларга тиеш түгел. Аллаһы сүбхәәнәһү вә тәгалә, Коръән Кәримдә болай дип әйтә: **"Үлем килгәнгә кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл!"** ***("Хиҗер" сүрәсе, 99 нчы аять).*** Рамазан аенда гына гыйбадәт кылып, изге ай тәмамлангач гыйбадәтләрне калдыру, мәчеттән һәм җәмәгатьтән ерагаю - зур хата һәм адәм баласы өчен куркыныч нәрсә. Һәр мөселман өчен ике Гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көненең фазыйләтләренә аерым тукталып үтәсе килә. Аллаһның рәсүле Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең хәдисләрендә әйткән:

■ "Чынлыкта, җомга көне - атнаның башка көннәренең хуҗасы, ул аларның арасында бөегрәге һәм Аллаһ каршында Рамазан вә Корбан гаетеннән дә бөегрәк. Ул биш вакыйга белән билгеләнә: Аллаһ ул көндә Адәм галәйһиссәламне халык кылды, ул көндә Аллаһ Адәм галәйһиссәламне Җиргә сөрде, ул көндә Аллаһ Адәм галәйһиссәламнең җанын алды; ул көндә бер сәгать бар, шул сәгать дәвамында кол нәрсә генә сораса да, ул аңа, һичшиксез ки, бирелер (әгәр дә ул тыелганны сорамаса һәм ул сәгать ирешсә). Һәрбер якын булган фәрештә, һәрбер күк, һәрбер җир, җил, таулар һәм диңгезләр җомга көн каршында калтырап торыр" (Ибне Маҗәһ).

■ "(Көндәлек) биш вакыт намаз, (алдагысыннан соң һәр киләсе) җомга намазында катнашу, (алдагы рамазаннан соң киләсе һәр) рамазанның уразасын үтәү, болар арасында (кылынган гөнаһларга) кәффарәт була, әгәр бу гөнаһлар арасында зур гөнаһлар булмаса" (Мөслим).

■ *"Әгәр кем дә булса җомгага көнне госел кылса, булдыра алган кадәр (яхшылап) пакьләнсә, (чәчләренә) өендә табылган ислемайларны сыласа (яки: ...(тәненә) сөртсә) аннары (җомга намазына) китсә, (мәчеттә) янәшә утыручыларга төрткәләмәсә, (Аллаһ) аңа билгеләгән намазны үтәсә, ә аннары имам сөйләгәндә эндәшмичә тик торса, аның бу һәм алдагы җомга арасында (кылган гөнаһлары), һичшиксез, гафу ителер" (Бохари).*

Аллаһ Раббыбыз Кәламе шәрифтә җомга көне турында болай дип әйтә: **"Ий мөэминнәр! Әгәр җомга көнне җомга намазына азан әйтелсә, эшләрегезне вә сәүдәләрегезне куеп намаз укырга, вәгазь тыңларга ашыгып барыгыз. Бу эш сезнең өчен хәерледер, әгәр бу эшнең файдасын белсәгез"** ***("Җомга" сүрәсе, 9 нчы аять).***

... Күпләр өчен ислам диненә керешү ураза тотудан башлана. Кеше ураза тотып, иң әүвәл үзенең ризыкка булган нәфесен җиңә. Аның үзенә булган ышанычы арта, денсезлеккә (дин тотмаучылыкка) каршы иммунитеты барлыкка килә. Ул үзенең Аллаһның колы булуын аңлый, Раббысына итагать итә (буйсына) башлый, аның холкы тәрбияләнә, башкаларга мөнәсәбәте яхшыра. Аңа башкалар да иярә, җәмгыять сәламәтләнә, гаиләләр ныклы була, хатыннарыбыз бала таба башлый, ирләребез айнып, эшли башлый. Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны, укыган намазларыбызны, ул кылган изгелекләребезне, биргән садакаларыбызны кабуллардан кылсын, хатакимчелекләребезне гафу итсен, күңелләребездә нинди изге теләкләребез, изге уй-ниятләребез булса - шуларга ирешергә, дингә яңа килүчеләргә иманнарын куәтләргә, гыйлем эстәүчеләргә хәерле, файдалы гыйлемнәр алырга насыйп әйләсен, балаларыбызга, изге ният белән гамәл кылып, киләчәктә хәерле бәндәләр булуларын насыйп кылсын, үзебезгә сабырлыкны, күркәм холыкны, ихтирамны, күркәм мөгамәләне юлдаш кылсын. Изге бәйрәмебез барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын!

***Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге***

# КҮКТӘГЕ ТОРНАГА КАРАП, КУЛДАГЫ ЧЫПЧЫКНЫ ЫЧКЫНДЫРМЫЙК

**Ничә еллар динсезлектә торган халкыбыз тәмам дини тормыштан аерылган иде: качып-посып намаз укыса да, уразасын тотса да аны берләштерә торган Аллаһ йортлары - мәчет-мәдрәсәләр юк иде. Дин ирекле килгәч, мәчет-мәдрәсә бинолары салына, дәүләт карамагында булган, иске биналар кире кайтарыла башлады. Шуның белән бергә алга бу биналарны тоту, җылысына, утына-суына түләү проблемасы килеп басты. Шулай итеп, дин тарату, халыкка ислам динен ирештерү икенче планда калды. Әмма алда әйтелгән проблемаларның икенчесе катлаулырак булып, бүгенге көндә дә тиешенчә чишелә алганы юк. Чөнки байлар, эшмәкәрләр бина алу, салу, искесен төзәтү эшенә теләп алынсалар да, салынган биналарны тоту мәсьәләсендә ярдәм күрсәтергә ашыкмыйлар. Бу проблеманы хәл итүдә имамнар төрле юллар эзли. Кемдер бинаның бер өлешен арендага бирә, кемдер спонсор ярдәменә таяна.**



Мин Ак мәчет бинасына 1996 нче елның апрелендә мәчетнең имам-хатыйбы һәм мәдрәсәнең ректоры буларак килдем. Биредә мәчет аерым, мәдрәсә аерым һәм алардан башка ислам диненә бернинди катнашы булмаган 6 оешма эшләрен алып бара иде. Мин бинаны арендага бирү алымын кабул итмәдем һәм 2 ел эчендә мәчет-мәдрәсәдән башка бөтен оешмаларны бинадан чыгарып бетердем. Чөнки мәчетнең бөтен эше халыкка дин тарату түгел, бәлки үзен-үзе тоту гына булып кала, ягъни исеме бар җисеме юк. Мин спонсорларга да таянмадым. Чөнки бирегә "Йолдыз" мәдрәсәсеннән килдем һәм дин таратуда спонсорларның нинди роль уйнаганнарын аңлый идем. "Йолдыз" мәдрәсәсенең миннән соңгы эшчәнлеге моны ачык күрсәтте.

Беренче көннән үк мәчет-мәдрәсә бербөтен булып эшләргә тиеш дигән максатны алга куйдым. Минем фикеремчә, шулай булганда гына халыкны дингә тартып, мәчетнең һәм мәдрәсәнең эшчәнлеген дөрес алып барып була. Шәкерт мәдрәсәдән яхшы әхлаклы, төпле белемле, халык белән эшли алырдай булып, ягъни халыкны тәрбияли торган күркәм үрнәк булып чыгарга тиеш. Моның өчен шәкерт үзенең киләчәген мәдрәсәдә үк күрергә тиеш. Димәк, мәдрәсәдә бер төрле сөйләп, мәчеттә икенче төрле эш алып барып тиешле нәтиҗәгә ирешеп булмый.

Дин тоту ирекле булып, мәчет-мәдрәсәләр эшли башлагач, йола башкаруны да үзәкләштерергә, системалаштырырга кирәк иде. Шушы максатны күз алдында тотып, Россиядә беренче булып Ак мәчеттә "Исем кушу", "Никах уку" һәм "Күмү" турында таныклыклар бирелә башлады. Без фәкать татар-мөселман исемнәре генә кушабыз, никахларны да мөселманнарга гына укыйбыз һәм бу йолаларны өйдә генә үтибез. Чит исемнәр булган очракта татар-мөселман исеме булырга, катнаш никах булганда икесенең дә бер диндә булырга тиешлеген аңлатабыз. Безнең болай эшләвебез милләтебезнең киләчәге өчен гаять файдалы бер гамәлдер.

Советлар Союзы таркалгач, халкыбыздагы рухи бушлыкны тутырырга дип бик күп диннәр, дини секталар баш калкытты. Аларны тарату өчен күп миллиардлар тотыла, бу бит халкыбызны коллыкка төшерүгә юнәлдерелгән һәм максатчан алып барыла торган сугыш. Мәҗлесләр уздырып, мәчетләрдә дога кылып утырып кына аларга каршы торып булмый. Шуларны күздә тотып, якшәмбе мәктәпләренә зур игътибар бирелде. Бүгенге көндә Ак мәчеттә 67 төркемдә 1000 нән артык кеше белем ала. Бу укуларны дини урта белемле 46 укытучы алып бара. Мәдрәсә тәмамлаган булуларына карамастан, укытучылар дини белемнәрен даими үстерү өстендә эшлиләр. Бу безнең уку-укыту системасына куелган таләпләрнең берсе. Укытучыларга белемне мәдрәсә мөгаллимнәре бирә.

Авыл халкының белемгә булган ихтыяҗын искә алып, 1998 нче елда Тукай районы имамнарының белемнәрен күтәрү курслары оештырылды. Шуннан соң ел саен бу курсларда имамнар үзләренең белемнәрен күтәрделәр һәм нәтиҗәдә бүгенге көндә экстремистик юнәлешләр үтеп керә алмаган үрнәк район булып саналабыз. Бу курслар 2004 нче елдан 2012 нче елга кадәр Татарстан Республикасы имамнарының белемен күтәрү институты буларак эшләде. Анда барлыгы 1000 нән артык имам белемен күтәрде. Татарстаннан гына түгел, бәлки чит төбәкләрдән дә: Башкортостаннан, Удмуртиядән, Киров өлкәсеннән, хәтта Иркутск өлкәсеннән дә килеп укыдылар. Бу уңышларга мәчет-мәдрәсәнең бер комлекс булып эшләве нәтиҗәсендә генә ирешеп булды. Шушы эшнең башында дәүләт лицензиясенә ия булган мәдрәсә тора. Милләт өчен булгач, укытуыбыз да үз ана телебездә алып барыла. Ак мәчет коллективында укып һәм укытып тәҗрибә туплаганнардан 2 се - казый, 4 е - мөхтәсиб, 30 ы Татарстанда һәм 10 ы Башкортстанда - имамлык һәм 100 ләп хатын-кыз мөгаллимлек вазыйфасын башкара. Ә инде мәчет-мәдрәсәнең бүгенге эшчәнлегенә күз салсак, биредә берьюлы 300 шәкерт мәдрәсәнең көндезге, кичке һәм читтән торып уку бүлекләрендә, 1000 нән артык шәһәрдәшебез якшәмбе мәктәпләрендә белем ала, 50 ләп имам ел саен үзенең белемен күтәрә. Татарстан Җөмһүрияте мөселманнарының Диния нәзарәте тарафыннан 19 нчы тапкыр уздырылган "Балаларның Россиякүләм Коръән уку бәйгесе" дә Ак мәчет бинасында безнең коллектив ярдәме белән оештырыла.

Без белем бирү белән беррәттән бинаны төзекләндерү, аны мәчет-мәдрәсә таләпләренә туры китереп үзгәртү эшләре белән дә шөгыльләнәбез. Нәтиҗәдә бүгенге көндә бинада 1500 кеше Гает намазларын укый ала. Нинди күркәм тәһарәтханәбез, спортзалыбыз, һәм 150 урынлы актлар залыбыз бар. Болар барысы да мәхәллә халкы тырышлыгы белән төзелде һәм барлык эшләр дә мәхәллә халкыннан керә торган садакалар исәбенә алып барыла.

Соңгы вакытта "социаль ислам" дигән төшенчә модага керде. Бу уйлап чыгарылган яңалык түгел. Ислам дине үзе социаль тигезлеккә, гаделлеккә нигезләнгән. Без дә күп еллар дәвамында фитра садакасының бер өлешен опека бүлегендә исәптә торган ятим балаларга бирдек. Мәчет территориясендә корбан чалыну тыелганга кадәр корбан итенең бер өлешен ятимнәр йортларына, психоневрологик диспансерга, мохтаҗларга өләштек. Ак мәчеттә бүген дә алда санап кителгән йола башкару мәҗлесләреннән садака алып кайту максат булып тормый. Бирелгән садакаларны мохтаҗ гаиләләрнең үзләрендә калдыру имам тарафыннан таләп ителә торган күркәм бер гадәт. Мәдрәсәгә инвалид балаларны да кабул итәбез, аларга да бөтен шартлар тудырып, тиешле белемне биреп чыгарабыз.

Кеше бүгенге көн таләпләрен канәгатьләндерә торган эшләр генә эшләсә, бернинди алга китү булмас иде. Без дә болар белән генә чикләнеп калмадык. Узган ел мәчет-мәдрәсәнең 20 еллыгын Казан, Чаллы югары уку йортларыннан төрле дәрәҗәдәге галимнәр чакырып республикакүләм фәнни-гамәли конференция буларак үткәрдек. Темасын да, мәчет-мәдрәсәнең 20 еллык эш нәтиҗәсе буларак, шәһәребездәге тынычлык, тотрыклылыкта Ак мәчетнең тоткан ролен искә алып, "Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда ислам диненең әһәмияте" дип атарга булдык. Моның белән генә чикләнеп калмадык, узган уку елында галимнәр белән бергәлектә 15 чара: лекцияләр, семинарлар, түгәрәк өстәлләр оештырдык. Мәчет-мәдрәсәбездә зур дәрәҗәле галимнәр белән очрашу традициягә әйләнде. Без бу чараларны мәдрәсә шәкертләре белән генә, мәдрәсә кысаларында гына түгел, бәлки мәхәллә халкы белән бергәлектә шәһәр күләмендә оештырдык. Мәсәлән, "Мөселман хатын-кызларының җәмгыятьтәге роле" дип аталган семинарда шәһәребезнең күренекле табиплары, хокук органнары вәкилләре, галимнәр һәм шәригать белгечләре катнашты. Югары уку йортларына барып, студентлар белән төрле очрашулар да үткәрәбез. Шулай ук яшьләр һәм шәкертләр белән бергәлектә төрле спорт уеннары, "Могҗизалар кыры", "Коръән уку", "Азан әйтү" ярыш-бәйгеләре мәчетебездә даими үткәрелеп килүче чараларга әйләнде. Без быел халыкка ике яңа проект белән чыктык. Беренчесе - "Изгелек эшләргә ашыгыгыз!" дигән акция кысаларында халыкка өндәмәләр таратабыз. Икенчесе - "Кем ничек ислам дине кабул итте?" дигән темага иншалар конкурсы игълан ителде. Конкурс ахырында җиңүчеләр билгеләнәчәк һәм бу иншалар җыентык итеп бастырылып чыгарылачаклар.

Халыкка дин таратуда бер чара да читтә калырга тиеш түгел. Без дә конференцияләр үткәреп кенә калмыйча, ул конференцияләрнең барышын яктырткан 2 зур күләмле җыентык, "Ак мәчет тарихы" дигән китап бастырып чыгардык. Гомумән, мәдрәсә остазлары тарафыннан 20 дән артык дини һәм фәнни китап бастырылды. Дәүләт радио-телевидениесе һәм вакытлы матбугат чаралары белән дә хезмәттәшлек итәбез. Бүгенге көндә үз студиябез, "You Tube"та үз каналыбыз һәм даими яңартылып торучы үз сайтыбызның да булуы халыкка ислам дине таратуда зуррак мөмкинлекләр ачты. Шушы алып барыла торган эшнең дәвамы буларак бу елның 2 мартында 1 Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен уздырдык.

Динне йола үтәү белән генә чикләргә кирәк түгел. Дин ул безнең тормышыбыз. Тормышыбыз үз эченә дини йолаларны да, гыйбадәтләрне дә, фәнне дә, гамәлләребезне дә ала. Шушыларның бөтенесен дә тиешле дәрәҗәдә игътибар биреп алып барганда гына милләтнең киләчәгендә алга китеш булырга мөмкин. Без Ак мәчеттә шуңа омтылабыз да инде.

Әгәр дә татар мәхәлләсен торгызуны бер калыпка куып кертергә телибез икән, алдан ук аның уңышсыз тәмамланачагына әзер булырга кирәктер. Чөнки татар халкы бөтен дөньяга чәчелгән. Кайсы илдә, кайсы җирдә булуына карап шартлар да төрлечә. Хәтта авылның бер башы икенче башыннан аерыла. Гомуми бердәм калып - без теле, ләкин үти алмый торган бер хыял. Күктәге торнага карап кулдагы чыпчыкны ычкындырмыйк. Кулдагы чыпчык ул безнең мәчет-мәдрәсәләр. Милләтнең киләчәге мәчет-мәдрәсәләрдә хәл ителә. Иң элек аларның бүгенге эшчәнлеген тәэмин итәргә кирәк. Әгәр бүгенге көнебезне кулдан ычкындырсак, иртәгә аны кайтарып булмаячак.

***Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,***
***Татарстанның Кама буе төбәге казые,***
***Чаллы шәһәренең Ак мәчете имам-хатыйбы***

# ЗӘКЯТ

***Хәлле мөселманнар елына бер тапкыр ярлы дин кардәшләре файдасына үзләренең мал-мөлкәтләреннән 2,5% куләмендә зәкят түләргә тиеш. "Зәкят" "чистарыну" дигәнне аңлата һәм ул исламда үзенчәлекле салым булып тора.***

Зәкят түләү исламда фарыз санала, ягъни ирекле рәвештә түләнелә торган сәдака (хәер генә түгел). Бездә булган бар нәрсәнең чын хуҗасы - Аллаһы Тәгалә. Ул сезгә башка мөселманнарга караганда күбрәк өлеш чыгарган икән, димәк, сез үзегездән арткан малыгызны мохтаҗлыктагы кешеләр белән бүлешергә тиеш.

Зәкят кеше көндәлек тормышында файдалана торган милектән - торак, транспорт, кием-салым яки хуҗалык кирәк-яракларыннан түләнми. Зәкятне бары ел дәвамында тотылмыйча сакланган акчасы, алтын-көмешләре, йорт хайваннары, сатыласы милке һ.б. булган кеше генә түли.



Матди яктан хәлсезрәк мөселманнар баераклардан хәер сорарга тиеш түгел, чөнки алар зәкят алырга хокуклы, ә хәллерәкләр исә, аларга милекләреннән өлеш чыгарып, үзләренең дини бурычларын үтиләр.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә зәкят алырга хокуклы кешеләрне билгеләгән. Зәкят бернинди милке булмаган һәм үзләрен туендырырлык акча эшли алмаган фәкыйрьләргә, ярлыларга, үз әҗәтләрен үзләре түли алмаган кешеләргә, күптән түгел генә исламны кабул иткән һәм ярдәмгә мохтаҗ булганнарга, сатып алганнан соң азат ителә торган колларга, үзләрен ислам диненә хезмәт итүгә багышлаган кешеләргә һәм сәфәрдә мохтаҗлыкка очраган юлчыларга түләнә.

Милектән зәкят түләгәннән тыш, мөселманнар елга бер тапкыр, рамазан ае тәмамланганнан соң, чистарыну сәдакасы да (фитыр зәкяте) түлиләр. Мөселманның әлеге хәерне ярлылар файдасына түләве мәҗбүри булсын өчен, һиҗри ел дәвамында билгеле күләмдә мал-мөлкәте булу шарт итеп куелмый. Шушы төр зәкят түләнә торган бәйрәм көнне генә милегең булу да җитә.

Аллаһы Тәгаләнең илчесе Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәсәлләм мөселманнарны саранлыктан һәм мал җыюга хирыслanудан сакланырга өндәгән. Милек җыеп та аннан тиешле зәкятен түләмәгән кешене үлеменнән соң җәза көтә. Зәкят фәкыйрьләрне көнләшүдән, байларны саранлыктан арындырырга һәм җәмгыятьтә ярлылар белән хәлле кешеләр арасында уңай мөнәсәбәтләр булдырырга ярдәм итә.

***"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән***

**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә "Зәкят" хәйрия фонды эшләп килә (аның адресы: Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт). Зәкяткә кагылышлы барлык өстәмә мәгълүматларны шуннан алырга мөмкин. Аллаһ Раббыбыз барчабызны да Үз рәхмәтеннән аермаса иде!**

# КАДЕР КИЧӘСЕ ЯКЫНЛАША

***Ислам динендә Кадер кичәсе бик олуг, изге кичәләрдән санала. Коръәни-Кәримнең 97 нче сүрәсендә: "Дөреслектә, Без Коръәнне иңдердек кадер кичәсендә. Син беләсеңме, нинди кичә ул кадер кичәсе? Кадер кич, мең айдан да хәерлерәк. Бу кичтә, фәрештәләр вә Җәбраил галәйһиссәләм иңәр (җиргә), Раббыларының әмере белән һәр эштә тынычлык булыр. Таң атканчы дәвам итәр бу кичә", - диелә.***

Кадер кичәсенең башка кичәләр арасыннан сайланып алынуының сәбәпләре турысында галимнәребезнең фикерләре күп. Бу сүрәдә, аның олуглыгын раслап, "Кадер кичәсе" дигән сүз өч мәртәбә искә алынган. Бу кичәнең дәрәҗәсе дөрестән дә олы, чөнки бу кичәдә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәдне (с.г.в.) пәйгамбәр итеп сайлый. Җирдә яшәүче бар халык өчен Коръән иңә башлый.

Мең айдан да хәерлерәк дип әйтү бу кичәдәге эшләнгән изгелекнең мең ай эчендә кылынган якшылыкларга караганда хәерлерәк икәне, ягъни сәваплырак икәне аңлашыла. Фәрештәләрнең җиргә иңүләре Аллаһның бу кичәдә кешеләргә мәрхәмәтлелеген күрсәтә. Гөнаһларның гафу ителүе, дога кылучыларның догалары кабул ителәчәге аңлашыла.

Кадер кичәсенең билгеләре: бу кичтә артык җилле, болытлы, тынычсыз һава торышы булмас. Төнге күктән йолдызлар атылмас. Шул төн арты кояш нурсыз пакь тулы ай кебек чыгар.

Кадер кичәсе елга бер мәртәбә Рамазан аенда гына була. Рамазан аеның, чыннан да, кайсы кичәсендә булганын бер Аллаһ Үзе генә белә. Шулай булса да, Пәйгамбәребез (с.г.в.) аркылы ул кичнең ай ахырында булуы хакында берничә хадистә белгертә. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Кадер киче Рамазан аеның сонгы ун кичәсе арасыннан эзләгез", - дигән. Башка бер хадистә: "Кадер кичәсен айның соңгы ун кичәләренең бүленми торган санга туры килгәне арасыннан эзләгез", - дип әйтелгән. Пәйгамбәр (с.г.в.): "Кадер киче 27 нче яки 29 нчы кичтер. Бу кичәдә фәрештәләрнең саны җирдә булган вак ташлардан да күбрәк булыр", - дип әйткән.

Галимнәрнең кайберләре, ул рамазан аеның 27 нче кичәседер, дип әйтәләр. Мөселман илләрендә дә гадәткә кергәнчә, 27 нче кичә кадер кичәсе итеп билгеләнә. Мөселманнар бу кичне бәйрәм көннәрендәге кебек мәчетләргә барып, намазлар укып, садакалар биреп, догалар кылып уздыралар. Ураза тоткан кешеләр рамазан аендагы ахыргы ун кичнең һәрберсенә игътибарлы булалар.



# БӘЙРӘМ ХӨТБӘСЕ

***/БЕРЕНЧЕ ХӨТБӘ/*** Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәру, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу үәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәүүәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти үәл-иимәән, үә шәрахә судүүрас-садикыйинә би шәрхил-һидәәйәти үәл-гыйрфәән, үә әкрамә гыйбәәдәһүл-муэминиинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәру, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу үәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саaимиинә әбүәәбәр-рахмәти үәл-гуфраан, үә галләка галәс-саaимиинә әбүәәбән-нийрани фи шәһри рамәдаан. Үәгадә лис-саaимиинә духуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лилҗәннәти бәәбән йүкаалү ләһүрраййәән. Ләә йәдхулүү-һүү илләс-саaимүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләзии үңзилә фииһил-куръәәнү һүдәл-линнәәси үә бәййинәәтим-минәл-һүдәә үәлфүркаан, Аллаһу әкбәру, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу үәллаaһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу үәхдәһүү ләә шәриикә ләһүү зүл-гафьүи үәл-гуфраан, үә әшһәдү әннә Мүһәммәдән габдүһүү үә расүүлүһүү. Салләллаahү Тәгаалә галәйһи үә галәә әәлиһи үә әсхәәбиһии саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән.

Әййүһәннәәс, үүсыйикүм гыйбәәдәллааhи үә нәфсии әүүәлән-битәкъүәллааh. Әгүүзү билләәhи минә шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааhә мәгаллләзиинәт-тәкау үәлләзиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааhү ләнәә үә ләкүм фил-куръәәнил-газыйим, үә нәфәганәә үә иййәәкүм бил-әәйәәти үәззикрил-хәкиим, иннәһүү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-газыйиму сәмиигуд-дүгааъә.

***/ИКЕНЧЕ ХӨТБӘ/*** Иннәлхәмдә лилләәhи нәхмәдүһүү үә нәстәгыйинүһүү үә нәстәгъфирүһүү үә нуъмину биһии үә нәтәүәккәлү галәйһи үә нәгуузү билләәhи миң шүрүури әңфүсинәә үә миң сәййиәәти әгъмәәлинәә мәййәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү үә мәй-йүдълилһү фәләә һәәдиә ләh. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу үәхдәһүү ләә шәриикә ләh, үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүh. Аллаһүммә салли үә сәллим галәә җәмигыйль-әнбийәәи үәлмүрсәлиин, үә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиин. Үә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйин, үә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйин, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-ардыйин. Аллаһүммә гъфир лилмүэминиинә үәл-мүэминәәт, үәлмүслимиинә, үәл-мүслимәәт, әләхъйәәи минһүм үәл-әмьүәәт, үәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

# УРАЗА ГАЕТЕ ХӨТБӘСЕНЕҢ ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘСЕ

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән.

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһка гына мактау. Аллаһка якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) вә иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидәят һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына рамазан ае уразасын бүләк иткән зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Барча мактаулар Аллаһка булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһ) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: "Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа Раян диелә. Ул ишектән рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс". Аллаһ Коръәндә әйтә: "Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр". Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Барча мактаулар Аллаһка булсын. Аллаһтан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу итүче һәм мәгъфирәт иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд - Аның колы һәм рәсүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сахабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһның коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһка сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән. Аллаһ Коръәндә әйтә: "Чынбарлыкта, Аллаһ тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә". Аллаһ безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта Ул (Аллаһ) гафу итүче, рәхимле, юмартлык иясе, олуглык иясе, бөек зат һәм догаларны ишетүче, кабул итүче.

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһка, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһка үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидәят бирсә, аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса - аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһтан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд - Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә - булсыннар алар күк әһелләреннән һәм булсыннар алар җир әһелләреннән - барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң рәхимлесе.

# РАМАЗАН ЙӨРӘКЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРДЕ

## Татарстан башкаласының "Kazan-Arena" футбол стадионында II республикакүләм ифтар уздырылды

**Ифтарга килгән халыкка ишек төбеннән үк намазлык һәм су тутырылган шешәләр таратып, волонтерлар кая барасын күрсәтеп-аңлатып торды. Башта стадионга куелган мөнбәр янына басып, республиканың танылган дин әһелләре - баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан мөфтие беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Голәмалар шурасы рәисе Габдулла хәзрәт Әдһәмов, Колшәриф мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов, республиканың төбәк казыйлары, имамнар халыкка динебез кыйммәтләре турында саф татарча вәгазьләр сөйләде. Аларның һәркайсы, бөтен республикадан халыкны җыеп (бирегә автобусларда ерактан килүчеләр дә күп иде), шундый зур ифтар мәҗлесе оештыручыларга, ачык рәвештә дин тоту һәм бүгенге кебек ифтарлар үткәрү мөмкинлеге биргән дәүләт һәм республика җитәкчелегенә рәхмәт сүзләре белән мөрәҗәгать итте.**



ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сөйләгән вәгазе рамазан уразасын тотуның, намаз укуның мөселманнар өчен әһәмияте турында булып, ул изге Коръән сүрәләре, хәдисләр, риваятьләр белән дәлилләнде. "Мондый ифтар мәҗлесләре йөрәкләрне берләштерә. Без бүген төрле социаль хәлдәге кешеләрнең берләшүен күрә алдык - Президенттан алып гади эшчегә кадәр барыбыз да бергә. Бу - безнең динебезнең нигезе", - диде Камил хәзрәт.

Ахшам намазын җәмәгать белән урам якка чыгып укыганнан соң, халык стадион холлында ир һәм хатын-кызларга аерым корылган табын янына урнашты. Әйтүләренчә, ифтарга тонна чамасы пылау пешерелгән, башка төр нигъмәтләр дә мулдан әзерләнгән иде. Ифтар кылганнан соң яше-карты, баласы-чагасы үзара гәп куертып, хис-кичерешләре, дөнья хәлләре турында фикер алышты. Аннары табынга, Аллаһы Тәгаләдән күпмилләтле Ватаныбызның чәчәк атуын, халкын иминлектә яшәтүен сорап, дога кылынды.

Стадионның медиа-фасадында исә Украина качакларына һәм башка мохтаҗларга ярдәм йөзеннән 7715 номерына "закят" сүзе җыеп смс җибәреп булуы турында реклама, "Хузур" нәшрият йорты әзерләгән социаль роликлар күрсәтелеп торды.




Республика ифтарында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Премьер-министр Илдар Халиков, Президент Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Дәүләт Советы депутатлары һәм башка рәсми затлар, чит илләрдән, Россия төбәкләреннән килгән кунаклар катнашты. Шулай ук күп балалы гаиләләр, инвалидлар, сукыр һәм начар ишетүчеләр, ярдәмгә мохтаҗлар да чакырылу иде. ТР мөселманнары Диния нәзарәте, РФ Мөселман эшкуарлар ассоциациясе, "Казан-Арена" стадионы дирекциясе оештырган республикакүләм ифтарда барлыгы 3 меңгә якын кеше кунак булды.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин сүзләренә караганда, киләсе елга ифтарны Казанда Россия күләмендә уздыру күздә тотыла.

***"Татар-информ"***
***Фотолар dumrt.ru, president.tatarstan.ru, tatar-inform.ru, business-gazeta.ru сайтларыннан алынды***


















A 103



# ҖАНЫБЫЗДАГЫНЫ ЧИТТӘН ЭЗЛӘРГӘ КИРӘКМИ

**Соңгы елларда Россиядә, шул исәптән Татарстанда да, төрле рухи турларга мода башланды. Кешеләр дини традицияләре белән танылган Непалга, Тибетка һәм башка экзотик илләргә юл тоталар. Монда гаҗәпләнерлек берни дә юк. Зур шәһәрләрдә яшәүчеләрнең, бертуктаусыз уңыш артыннан куудан арып, бетмәс мәшәкатьтән арынасылары килә. Ләкин моның өчен туроператорларга мөрәҗәгать итәргә кирәк микән?**

### ТЫШКЫ РИТУАЛЛЫК

Моның белән бәйле рәвештә узган ел Корбан бәйрәмендә корбан итеп чалу өчен республикабызга дөяләр алып кайтучы эшкуарны искә төшерми мөмкин түгел. Дини тәгълимат буенча дөяләрне корбан итеп чалырга була анысы. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә нәкъ менә дөя чала торган булган. Ләкин бу очракта бер мөһим нәрсә бар. Аллаһы Тәгалә Илчесенең (с.г.в.) гамәле ул яшәгән җирлек өчен килешкән. Безнең очракта болай эшләү корбан чалуның төп мәгънәсен - кешеләргә булышуны югалтуга китерергә мөмкин. Корбан ите мохтаҗлар һәм ризыкка тилмерүчеләр өчен бит. Шуңа күрә 200 мең сумга бер дөя сатып алганчы, берничә сыер сатып алу хәерлерәк. Күбрәк кешегә җитә, мәшәкате дә азрак.

Непал яки Тибетта рухи тынычлык эзләү, минемчә, алда язылганнарга охшаш нәрсә инде. Бу очракта тышкы ритуаллык бик зур. Теләсә кайсы Тибет ламасы сезгә рухи юлда эзләгәнебез кайдадыр еракта түгел, ә үзебездә, җаныбызда булуын раслаячак. Әлеге билгеле хакыйкатьне ишетү өчен шулкадәр еракка бару кирәк микән?

### КЫЙММӘТЛЕ ТАБЫШ

Ислам диненең кешегә дөнья артыннан кууны туктатырга, күңелеңдә тәртип урнаштырырга, тормыш ориентирларын карарга булышучы үз тәҗрибәсе бар. Шуларның берсе - игътикяф. Ул рамазан ае белән бәйле. Игътикяф изге айның соңгы ун көнендә уза. Ир-атлар аны мәчетнең намаз укый торган өлешендә, хатын-кызлар өйдәге намаз укый торган бүлмәләрендә үткәрәләр. Игътикяф дәвамында кеше үзен Алаһы Тәгаләгә зикер итүгә, дога, Коръән укуга багышлый. Дини китапларны укырга ярый, ләкин дөнья хәлләре турында сөйләшергә һәм күңел ачарга ярамый. Игътикяф кылу урынынан ул бары тик физиологик хаҗәтләрне һәм гигиена таләпләрен үтәү өчен генә чыгарга мөмкин.

Бүгенге заман кешесе өчен кешеләрдән читләшеп тору гамәле - бәяләп бетергесез табыш. Бертуктаусыз дөнья артыннан куу, һәрвакыт башкалар белән бәйләнештә тору кешенең эчке дөньясы бушауга китерә. Безнең чор кешесенең күктәге йолдызларга карау һәм, бер мизгелгә булса да туктап калып, күңеле халәтенә колак салу өчен вакыты юк. Якын кешеләре белән җылы аралашуны бергәләп телевизор каршында яки компьютер артында утыру алыштырды.

Безнең чор кешесе үзенә үзе хуҗа түгел. Ирек мәсьәләсенә килгәндә, ул ялланаяклы борынгы Мисыр колларына караганда да начаррак хәлдә. Чөнки һәрвакыт уйлары белән эштә, интернеттагы дуслары янында. Аның мондалыгын бары тик гәүдәсе генә белдереп тора. Башкача әйткәндә, аның иң кадерле нәрсәсен - тормышын "урлаганнар".

### ИКЕ ЯКНЫ ДА ТИГЕЗ ТОТАРГА КИРӘК

Эштә бертуктаусыз уңыш артыннан куудан арыган замандашларның кайберләре хәзер протест белдерә башлады. Шулай итеп, дауншифтерлар агымы барлыкка килде. Бу кешеләр аңлы рәвештә "уеннан" чыгалар, "чабудан туктыйлар" һәм: "Җитәр! Көпчәктәге тиен кебек бүтән йөгерәсебез килми. Безнең яшисебез килә: иҗат итәсебез, гаиләбез, күңелебезгә яткан шөгыль белән шөгыльләнәсебез килә",- дип белдерәләр. Соңгы чиктә дауншифтерлар барысын да ташлап, дөнья буйлап автостоп белән сәяхәт итә башлыйлар. Дауншифтерлар - бүгенге заманның авыруы билгесе. Бу - агрессив, кешегә каршы юнәтелгән тормыш кысаларына җавап. Ләкин үзеңне бу хәлгә җиткермәскә дә була бит.

Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) Аллаһы Тәгаләгә ышана торган кешене ике канатлы кош белән чагыштыра. "Аның бер канаты - бу дөньяда, икенчесе - ахирәттә", - ди ул. Башкача әйткәндә, Пәйгамбәребез (с.г.в.) кешеләрне гармониядә яшәргә өйрәтә. Дөнья эшләре, карьера һ.б. белән шөгыльләнү дә мөһим, ләкин рухи хаҗәтләр, эчке дөнья турында да онытмаска кирәк. Шул ук вакытта, рухи як белән шөгыльләнеп, дөнья турында онытырга, дәрвиш булып китәргә дә ярамый. Дөнья эшләренә дә вакыт һәм илһам табарга кирәк. Без ике якны да тигез тотарга омтылырга тиеш.

Үз юлыңның тигезлеген саклап калу өчен, ислам кешегә гамәлләрнең тулы бер җыелмасын тәкъдим итә. Мәсәлән, көндәлек мәшәкатьләрдән арындырып тора торган биш вакыт намаз бар. Шуның өстенә намаз үз эченә төрле хәрәкәтләр комплексын да ала. Безнең тыныч халәттә булуыбыз өчен бу да бик мөһим.

Игътикяф - психологик яктан янудан тирән һәм озак вакытка сузылган профилактика булып тора. Әлбәттә, мөселманнар игътикяфта күңелне ял иттерүне генә түгел, ә тирәнрәк мәгънә күрәләр. Бу Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт итүнең бер төре. Игътикяф практикасы әкренләп Татарстан мәчетләренең дә рухи тормышына кайта башлады.

### "СИН - ЧЫГАНАК"

Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) һәр рамазан аеның соңгы 10 көнен кешеләрдән читкә китеп үткәрә, ә үлгән елында 20 көн игътикяфта була. Шуңа күрә бу Пәйгамбәр (с.г.в.) нигез салган мөһим традициягә (сөннәткә) әйләнеп китә. Кыямәт көнендә өммәтебез Пәйгамбәребез (с.г.в.) яклавыннан мәхрүм калмасын өчен бөтен мөселман өммәтеннән аны бер кеше булса да башкарырга тиеш.

Әлбәттә, беркем дә кешегә рухи тынычлык, зирәклек эзләп, Тибетка яки башка бер җиргә баруны тыя алмый. Туристлык бизнесы бу яңа модага шат кынадыр, дип уйлыйм. Югыйсә акчаны җилгә очыруның башка юлларын да табып була, мәсәлән, үзеңә бриллиант дисбе ясатасың. Ләкин төп мәгънәне аңлаган кеше тышкы ясалма ялтыравыкка кызыкмый, чит илләрдә хакыйкать эзләми. Ул үз динен тирәнрәк өйрәнә һәм гыйбадәт кыла, һәм шулай ук Җәләледдин Руми сүзләрен еш исенә төшерә: "Син үзең - сөт чыганагы, башкаларны савудан тукта".

***Рөстәм БАТЫР,***
***Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары***

# ИГЪТИКЯФ

**"Игътикяф" сүзе көтү, нәрсәнедер дәвам итү дигәнне аңлата. Шәригатьчә игътикяф бер ир кешенең җәмәгать мәчетендә (игътикяф нияте белән) торуы. Яисә хатын-кызның өй мәчетендә (өендә намаз кыла торган урында игътикяф нияте белән) торуы. Җәмәгать мәчете, эчендә биш вакыт намаз кылыну-кылынмавыга карамастан, имамы һәм мөәзине булган мәчет ("Дүррүл Мохтар" һәм "Рәддүл Мохтар", 2 том, 440 б.).**

Мәчеттән чыгу игътикяфне боза. Игътикяф кылучы кеше көндезен дә, төнен дә игътикяф кыла торган урыныннан чыкмас. Ләкин берәр гафу ителерлек сәбәп белән чыга ала. Бернинди сәбәпсез бер мизгелгә генә чыкса, Әбү Һүрайра фикеренчә, игътикяф бозыла. Чыгуы махсус яки онытылып булса, игътикяф бозылу мәсьәләсенә охшаш. Кадиханның "Фәтава"сында да шулай диелгән. Хатын-кыз өендә игътикяф кыла торган бүлмәсеннән чыга алмый. Хатын игътикяфне мәчеттә кыла торган булып, ире аны кайтырга чакырса, өенә кайтып, игътикяфен шунда дәвам итәргә тиеш. Зур тәһарәт белән кече тәһарәт алырга һәм җомга намазына чыгу да сәбәп була. Игътикяф кылучы кеше зур һәм кече тәһарәт алу өчен мәчеттән чыга ала. Ләкин бу ихтыяҗларын үтәүгә үк кире мәчеткә керергә тиеш. Мәчетнең ишелүе куркынычы янаганда яки шуңа охшаш башка сәбәпләр булганда гына мәчеттән чыгу зарар итмәс. Кече яки зур тәһарәт алу өчен мәчеттән тышка чыккан игътикяф кылучы кешене, кире мәчеткә кереп киткәнче, бурыч алачагы булган берәү күреп алып дәшсә, Имам Әгъзам фикеренчә, игътикяф бозыла. Башка ике имам фикеренчә, бозылмый. Игътикяф кылучы кеше хастаның хәлен белергә яки җеназа намазына катнашу өчен мәчеттән чыга торган булса, игътикяфе бозыла. Хасталыгы сәбәпле мәчеттән тышка чыгуы да игътикяфне боза. Ләкин игътикяф кылырга нәзер әйтеп, хастаның хәлен белү, җеназа намазына катнашу



яки гыйлем мәҗлесенә әзерләнү өчен мәчеттән чыгу шартын да кушса, игътикяфе бозылмый. Игътикяф кылучы кеше берничә көнгә һушыннан язса яки тилерсә, игътикяфе бозыла. Савыккач, игътикяфен яңадан кыла башлар. Хәтта бу хәле берничә ел буе дәвам итсә дә, савыккач, игътикяфен каза кылырга кирәк була. Бу мәсьәләләр ваҗиб булган игътикяфкә бәйле...

Игътикяф кылган кешенең ашавы, эчүе һәм йоклавы мәчет эчендә була. Болар өчен мәчеттән тышка чыга торган булса, игътикяфе дөрес булмас. Игътикяф кылган кешенең, сөйләшмәүне бер гыйбадәт дип белеп, сөйләшмәве мәкруһ була. Моңа ышанмыйча сөйләшми торган булса, мәкруһ булмас. Хәерле нәрсәләрдән башка нәрсәләр турында сөйләшү мәкруһ була. Игътикяф кылган кеше манарага менеп азан әйтә ала.

***Камил СӘМИГУЛЛИННЫҢ***
***"Ураза" китабыннан***

*Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның үзенең дә быел Изге рамазан аеның соңгы 10 көнен игътикяфтә уздырырга нияте бар. Бу хакта ул ТҖ МДНнең журналистлар өчен үткәргән ифтар мәҗлесендә белдерде. Игътикяфне хәзрәт үзе имамлык иткән Тынычлык мәчетендә үткәрә. Бу аның беренче генә игътикяфе түгел. Мөфти хәзрәт алдагы 10 көн дәвамында ялгызлыкта калып, Аллаһы субхәнәһү вә Тәгаләдән туган республикабыз, аның халкы һәм җитәкчеләре өчен бәрәкәт-иминлек сорап гыйбадәт кыла.*

# МӨСЕЛМАН БАЛАЛАРЫ НИЧЕК ЯЛ ИТӘ?

**Июнь аенда бөтен җөмһүриятебездә мөселман лагерьлары гөрләп эшләде. Күп кенә мөхтәсибәтләр бу күркәм гамәлне рамазан ае тәмамланганнан соң да дәвам иттерергә булганнар. Балаларыгыз дин гыйлеменә, әдәп-әхлакка өйрәнсен, спорт белән шөгыльләнеп, сәламәтлеген ныгытсын дисәгез, әле соң түгел, ямьле җәйнең башланмаган тагын бер ае бар!**

Гомумән, балаларның җәйге ялын файдалы да, мавыктыргыч та итеп оештыру өчен мәхәлләләрдә күп тырышлык куела. Казанның Гаилә мәчетендә, мәсәлән, 28 нче июльдә Ураза бәйрәме уңаеннан балалар һәм аларның әти-әниләре өчен зур бәйрәм уздырырга җыеналар. Бу көнне балалар өчен төрле уеннар, мастер-класслар, спорт ярышлары оештырыла. Балалар күңелен күрер өчен аниматорлар, аквагримерлар чакырылган, батутлар куелачак. Моннан тыш нәниләрне тәм-томнар белән сыйлау да каралган. Балалар өчен оештырылган Гает бәйрәме көндезге 2 нче яртыда башлана. Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм Хәйруллин сүзләренә караганда, август аенда мәчет каршында лагерь да эшләячәк.

Буада исә балалар өчен мөселман лагере рамазан аенда да эшләп торган. Анда 25 малай һәм 10 кыз бала Коръән ятлау белән шөгыльләнгән. Аларга Россия ислам институты укытучылары һәм "Мөхәммәдия" шәкертләре ярдәм иткән.

Рамазан аенда Спас районының Ак мәчете һәм Әҗмер авылы мәчетләре каршында да лагерьлар эшләгән. Мөхтәсиб Фәрхәт хәзрәт Минсәгыйров әйтүенчә, бу балалар зур чарага әзерләнә икән - 9 нчы августта Болгарда Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Зәкят" хәйрия фонды белән берлектә Коръән уку бәйгесе уздырырга җыеналар.



## АВГУСТ АЕНДА КАЙСЫ МӨХТӘСИБӘТЛӘРДӘ МӨСЕЛМАН ЛАГЕРЬЛАРЫ ОЕШТЫРЫЛА

| Мөхтәсибәт | Мәчет/мәдрәсә | Ничә көнлек | Кемгә мөрәҗәгать итәргә | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|
| Алексеевск | җамигъ мәчеттә (Пушкин ур.) | 2 атна | Рөстәм Вальщиков, 89600542488 | |
| Азнакай | Ак мәчет (Мәрҗани ур.) | 2 атна | Азат хәзрәт Талибуллин, 89196334433 | кызлар лагере |
| Аксубай | җамигъ мәчет (Горький ур.,6) | 7-10 көн | Равил хәзрәт Зөфәров, 89172430716 | |
| | МЮД бистәсе | | | |
| | Иске Ибрай | | | |
| Актаныш | Күҗәкә | | Руслан хәзрәт Мортазин, 89372834680 | |
| | Чишмә | | | |
| | Әтәс | | | |
| Апас | җамигъ мәчет | 15 көн | Мирхәт хәзрәт Җамалиев, 89061159331 | |
| Әгерҗе | Ямурза | 1 атна | Азат хәзрәт Гатин, 89600677948 | |
| Әтнә | җамигъ мәчет (Татарстан,7) | 20 көн | Наил хәзрәт Сәгъдиев, 89600382376 | кызлар, малайлар сменалары |
| Буа | 5 нче мәхәллә | 10 ар көн | Илмир хәзрәт Хәсәнов, 89270382582 | |
| | Мәдрәсә (К.Либкнехт ур., 79) | | | |
| Биектау | Дөбъяз | 10 ар көн | Тәлгать хәзрәт Гайфуллин, 89372821771 | |
| | Кече Салабаш | | | |
| Зәй | җамигъ мәчет (Т.Ялчыгол ур.,16) | 2 атна | Сәгыйть хәзрәт Камалов, 89178515250 | |
| Кайбыч | җамигъ мәчет (Үзәк урам) | 7-10 ар көн | Дамир хәзрәт Гыйниятуллин, 89274421985 | |
| | Кышман | | | |
| | Борындык | | | |
| | Чүти | | | |
| | Бортас | | | |
| Кама Тамагы | җамигъ мәчет | 10 көн | Галимулла хәзрәт Яруллин, 89063296027 | |
| Кукмара | Өркеш | 2 шәр атна | Зиннур хәзрәт Сәмигуллин, 89196905868 | студент кызлар өчен |
| | Аш-Буҗи | | | мәктәп балалары өчен |
| Казан | Гаилә мәчете (Җ.Фәйзи ур., 2) | | Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, 2230662 | |
| | Апанай (К.Насыйри ур., 27) | | Нияз хәзрәт Сабиров, 2934292 | |
| Чаллы | Нур-Ихлас мәчете | 20 шәр көн | Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, 56-99-65 | |
| | Әбүзәр мәчете | | | |
| | Чишмә | | | |
| Сарман | җамигъ мәчет | 1 атна | Сәгыйть хәзрәт Хаков, (885559)26502 | чатырларда |
| Яңа Чишмә | җамигъ мәчет | 1 әр атна | Газизулла хәзрәт Зартдинов, 89872743411 | |
| | Сулчәбаш | | | |
| | Тубылгытау | | | |
| Тукай | Теләнче-Тамак | 11 әр көн | Җәүдәт хәзрәт Харрасов, 89270408002 | |
| | Яңа бистә | | | |
| Чирмешән | җамигъ мәчет | | Минсәгыйрь хәзрәт Миншин, 89274289196 | кызлар сменасы, урманда |
| Яшел Үзән | мәдрәсә (Ленин ур., 22а) | | Рамил хәзрәт, (884371)40473 | |
| Нурлат | мөхтәсибәт каршында | 3 атна | Айрат хәзрәт Әюпов, 89196332978 | “Заречье” лагеренда |
| Мамадыш | | 1 атна | Илһам хәзрәт Миннегалиев, 89196352943 | Кама буенда чатырларда, катнаш лагерь |
| Теләче | | 15 көн | Исмәгыйль хәзрәт Фәләхиев, 89050215852 | Сауш мәктәбе базасында, кунып яши торган - катнаш лагерь |



**ХАТЛАРЫГЫЗНЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНӘ (Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә *naubahar67@list.ru* адресы буенча җибәрә аласыз**



## ШӘКЕРТЛӘРГӘ АЧЫК ХАТ

Күптән түгел генә "Казан утлары" журналы хезмәткәрләре: журналның баш мөхәррире, шагыйрь Илфак Ибраһим, шагыйрә Гөлзадә Бәйрәмова белән мин фәкыйрегез "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә читтән торып укучы шәкертләр белән очрашкан идек. Сөйләшү кызыклы булды. Журналның киләчәге, сәясәт һәм дин мәсьәләләре турында сәгать ярым сөйләштек. Сораулар күп булды. Миңа да сораулар килде. Бертөркем шәкертләр исеменнән язылган иде ул хат. Хат ничек язылган булса, шулай китерәм. "Батулла әфәнде! Без Мәскәүдән интернет буенча "Ручка", читающая Коран сатып алган идек. Татарча тәфсирне сез укыйсыз. Һәм ялгышкан җирләрдә сез "ой" диеп куясыз. Ни өчен сез ялгышларны төзәтмичә, тикшермичә, тиражга рөхсәт бирдегез? Без сезне бик яратабыз, иҗатыгыз белән һәр чәк кызыксынабыз. Ә менә бу ялгышлар өчен безгә сезнең өчен бик оят."

Бу шәкертләргә мин очрашу вакытында җавап биргән идем инде, әмма газета аша ачык хат та язарга булдым, чөнки "Ручка, читающая Коран"ны бик күп имамнар, шәкертләр алдыра. Бу мәсәьәләгә ачыклык кертүне кирәк таптым.

Беренчедән, минем беркайчан да "Ручка" белән эш кылганым булмады.

Икенчедән, сез, "Ручка"ны тыңлаучылар минем тавышны башка берәүнең тавышы белән бутагансыз. Сезнең кулдагы тавышлы Коръәнне Илдар Кыямов укый, һич тә мин түгел. Чыннан да, Илдарның тавышы белән минем тавыш бераз охшаш. Сезнең кулдагы тавышлы Корьәннең азагында аның кем тарафыннан чыгарылганы һәм аятьләрне кем укыганы язылган булырга тиеш. Өченчедән, Кыямов укыган ул тәфсир минеке түгел, Ногманиныкы.

Бу хатны ни өчен яздым соң? Эшнең асылына төшенмичә фикер әйтү үзе ялгышка китерә, ә тавышлы Коръәннең башкарылышыннан канәгать булмавыгызны сез "Ручка" җитәкчеләренә яза аласыз. Бигайбә!

Шулай да, форсаттан файдаланып, шуны әйтәсем килә: үземнең тәфсирне тулысы белән тавышлы итеп чыгарырга исәбем бар, ул инде әзер булып килә, озакламый кулыгызда булыр, иншә Аллаһ!

***Рабит Батулла,***
***Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе***

## НӘГЫЙМӘ ӘБИ КЫЙССАСЫ

Моннан берничә еллар элек рамазан аенда булды бу хәл. Тәбрис ул көнне йокысыннан иртәрәк уянды. Башына килгән беренче фикере шул булды: нигә әле аңа да ураза тотып карамаска? Нәгыймә әбисе әнә бер көн уразасын калдырмый иде. Кояш көйдереп алырлык эссе көннәрдә дә авызына бер йотым су алмады.

... Тәбрискә 10 яшь тулган чагында аның Нәгыймә әбисе, Илсур абыйсының кызы Лилияне карарга дип, Казанга китеп барды. Әмма авылда чишмә суыннан гына кайнаткан чәй эчеп яшәгән әбисенә Казанның суы да, һавасы да килешмәде, ахры, бер ел да узмагандыр, аны параличланган килеш, авылга кайтарып куйдылар. Авызлары кыйшайган, аякларын да көчкә сөйрәп йөри. Соңгы елын бөтенләй дә ятакта үткәрде. Алып кайткан дарулар да килешмәде аңа. Әбисен искә төшерсә, Тәбриснең күңелен моңсу уйлар биләп ала. Теге чакта нигә ташлап китте икән соң ул аларны? Анда китмәгән булса хәзер менә исән булыр иде, бәлки... Ә 1968 нче елның көзендә ул аларны бөтенләйгә ташлап китте. Бүгенгедәй хәтерендә: Тәбрис бертуган абыйсы Һадиулла белән бакчадагы бәрәңге камылларын җыеп йөри иде, кайсыдыр өйдән чыгып: "Әбигез вафат булды!"-диде. Шул мизгелдә җир өсте кинәт караңгыланып китте, әйтерсең лә кояш сүнде...

... Менә шул Нәгыймә әбисе өйрәткән иде Тәбрисне ураза тотарга. Җимешләр салып тәмле чәй ясап, иртәнге якта татлы йокысыннан уята торган иде ул аны. Әй ул чәйнең тәме! Әмма әбисе бер чынаяк кына ясый. "Улым, артыгын эчәргә ярамый ул. Күп эчәргә өйрәнсәң, көндезен дә сусарсың",- дия иде. Бәләкәй булганлыктан, ул чакта Тәбрисне ураза тотарга кыстаучы юк, ә менә олылар тотмаса, яисә берәр көнен калдырса, ул инде гайре табигый хәл булып кабул ителә иде.

Бер елны рамазан ае бәрәңге алган вакытка туры килде. Җитмәсә, ул елны сентябрь аенда кояш рәхимсез кыздырды. Менә аның әбисе өйгә кереп китте. Бәрәңгеле капчыкны күтәреп, аның артыннан Тәбрис тә өйгә юл тотты. Өй ишеген ачып керсә, ни күрсен: әбисе хәлсезләнеп караватта ята. "Әби, әби, дим, мә эч инде", - дип ул су кисмәгеннән чүмеч белән салкын су алып әбисенә сузды. Әмма әбисе аның кулын читкә этәрде. "Юк, улым, хәзер үтә ул", - диде, үзе һаман эченнән ниндидер догалар кабатлады. Бераз гына ял итеп алгач, чыннан да, аның хәле яхшырды, улы белән килененең ай-ваена карамыйча, ул яңадан бәрәңге чүпләргә бакчага чыкты.

... Тәбрисләрнең өе зират янында гына. Кояш зәвәлдән төшә башлауга, аның нурлары, әйтерсең, агач ботакларына эленеп кала. Җиргә бу вакытта төрле сурәтләр төшә, бер карасаң, алар зур җанварны хәтерләтә, икенче караганда, җиләс иген кыры кебек. Рәхәт тә соң малайга шул агачның күләгәсендә басып торуы. Тик дөньяңны онытып озаклап басып торырга ярамый, каты яңгырлар ява башлаганчы бәрәңгене алып бетерәсе бар, юкса эш харап. Ә кичкә әтисе, әнисе һәм абыйсы өйгә кайткач, эш тагын да җанланып китәчәк. Әтисе: "У-у, улым, бүген яхшы ук алгансың",- дип аны мактап та куяр әле...

Бүген инде бу хәлләрнең һәммәсе дә татлы төш кебек кенә. Нәгыймә әбисе дә, әтисе белән әнисе дә бу дөньяда юк Тәбриснең. Балачагының тәүге уразасы да бик еракта калды. Быелгы рамазанны каршы алганда ул шул балачак хатирәләрен яңартып, газиз кешеләрен исенә төшерде.

***Хатип ГӘРӘЙ***

## БЕРЕНЧЕ СӘХӘР

Рамазан ае керүгә "келт" итеп балачагым, газиз әнием һәм беренче сәхәрем искә төшә.

... Мәктәптә укымый идем әле. Бер төнне ничектер йокымнан уянып китеп, әниемнең почмак якта ялгызы гына чәйләп утырганын күрдем. Бу рамазан уразасының беренче сәхәре булган икән. Сикереп торып мин дә әни янына килеп утырдым. Әнием калын итеп ипи кисте, өстенә бик тә калын итеп каймак якты да миңа сузды. И-и аның тәмлелеге... Әнием үзенә генә дип пешергән булгандыр инде, тастымал астыннан алып, минем алдыма йомыркалар куйды. Тамак туйгач, берзаман йокы да килә башлады. Әнием: "Бар, улым, рәхәтләнеп ятып йокла инде", - диюгә караватыма йөгердем.

Мин торганда кояш шактый кыздыра иде. Рәхәт, көн матур. Торып киендем дә урамга йөгердем. Авылыбыздагы ике коеның берсе янына җыйналган малайлар мине: "Син кайда йөрисең?"- дип каршы алдылар. Уйнаганбыздыр инде, хәтерләмим. Берзаман Ревальнең: "Әйдәгез, Гөлсем апай алмасына барабыз", - диюе булды, дәррәү кубып авылның теге очына йөгердек. Элек Гөлсем исемле апа яшәп, инде йорт нигезе дә калмаган ташландык бакча ул. Ну алмасы бик тәмле иде...

Кичке эңгер-меңгер төшкәч кенә кайтып кергән кечкенә малайны өйдәгеләр борчылып каршы алдылар. Әнием: "Улым, ашыйсың килгәдер, әйдә, чәй эчеп ал. Әллә уразаны тотып бетерәсеңме?" - дип аркамнан сөйде. Ә мин чатнатып: "Юк, әни, уразаны тотып бетерәм. Мин алма гына ашадым", - дип җавап бирдем. Әниемнең көлемсерәп кочагына алуы истә...

***Хәмит БАДИКОВ,***
***Әтнә***

## "ОЯТЫ БУЛГАН КЕШЕ КИЧКЕ СӘГАТЬ УНДА АШАРГА ЙӨРМИ!"

Менә янәдән Изге рамазан ае житте. Ураза тотучының ике шатлыгы бар: берсе - ифтар, икенчесе - Кыяматтә хисап тоткан вакыты. Дөрестән дә, 19 сәгать буе ашау-эчүдән тыелып торганнан соң авыз ачу сәгатен бик зарыгып, шатланып көтеп аласың. Ифтар ул - һәрбер кеше өчен кечкенә генә бер бәйрәм кебек. Һәм шул бәйрәмне сине аңлаган кешеләр - мөселманнар белән бергә бәйрәм итәсе килә. Гаиләсе зур булган кешегә җиңелрәктер: аларның кичке ашлары ифтар мәҗлесе сыман бик күңелле үтәдер. Әмма ялгызлар, кечкенә гаиләле кешеләр өчен мөселман кардәшләре белән үткән ифтар мәҗлесләре бер сөенеч булып тора. Хикмәт ашауда гына түгел бит. Ифтарда үз нәфесләрен Аллаһка буйсындыручыларның күплеген күрәсең, һәм бу күренеш, һичшиксез, иман ныгуга сәбәп булып тора. Соңгы елларда өйдә авыз ачтыручыларның саны кимеде. Моның сәбәбе дә бар: кояш бату вакыты бик соң. Шул сәбәптән мәчетләрдә ифтар үткәрү киң таралган. Һәр мәчеттә диярлек көн дә ифтарлар үтә. Халык та бик яратып шул мәҗлесләрдә катнаша. Кайбер мәчетләрдә авыз ачучыларның саны 300 гә җитә. Нинди матур күренеш!

Бер кешене ифтар кылдыручыга ураза тоткан савап языла. Ифтарны әзерләүгә үз өлешен кертүчеләргә дә Аллаһы Тәгалә бихисап әҗер-савап вәгъдә итә. Шулай итеп, мин дә шул бәхетле төркемгә эләгү нияте белән ифтар әзерләшергә киттем. Бик тырышып табын әзерләп йөргәндә, бер кешенең әйткән сүзе мине шаккатырды. "Сәгәть унда ояты булган кеше ашарга йөрми!" - диде ул. Көч-хәл белән күз яшьләремне тыеп, тиз генә эшлисе эшләремне эшләп бетердем дә кайтып киттем. Ифтар әзерләүченең бу җөмләсе гамәле белән һич туры килми бит. Шулай фикер йөрткәч, ифтар әзерләүдә катнашуның ни мәгънәсе кала?

Кулыма каләм алуымның сәбәбе әлеге бәндәне тәнкыйтьләү түгел, киресенчә, изгелек кылучыларны кисәтү. Изгелек кылып, әҗер-саваплы булу - ул әле эшнең яртысы, икенче яртысы - шул әҗер-савапны Кыяматкә хәтле саклап, мизанга тапшыру. Кайвакытта шундый авырлык белән казанган әҗер-савапларны бер гамәл, бер сүз дә юкка чыгара...

***Гөлназ ГАЛИЕВА***
***Казан***

# ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ВӘЛИУЛЛА ХӘЗРӘТНЕ ИСКӘ АЛДЫ

**Шушы көннәрдә бер төркем дин әһелләре, чордашлары фаҗигале төстә арабыздан киткән танылган татар дин әһеле, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче һәм нәшир Вәлиулла хәзрәт Якуповны искә алды.**

Мөселманнар Вәлиулла хәзрәт имам-хатыйб булып эшләгән, төзекләндергән тарихи Апанай мәчете янына җыйналды. Анда имамнар, Вәлиулла хәзрәтнең чордашлары, җәмәгать эшлеклеләре, "Иман" нәшрияты вәкилләре, мәхәллә кешеләре хатирәләре белән уртаклаштылар, аның киң кырлы эшчәнлеген барладылар, татар халкына тырышып хезмәт итүен, мөселман өммәтенә бик күп файда китерүен искә төшерделәр. Аннан соң, танылган дин әһеле каберен зиярәт кылырга, рухына багышлап догалар укырга ниятләп, Вәлиулла хәзрәт җирләнгән Казан мөселман зиратына юл тоттылар.

Казан мөселман зиратына хәзрәтнең каберен зиярәт кылырга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе, Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров, Татарстан Президенты Аппараты Дини оешмалар белән эшләү идарәсе җитәкчесе Илнур Гатауллин һәм башкалар килгән иде.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Вәлиулла хәзрәтнең белемле дин әһеле булып, гыйлемне башкаларга китаплары, газеталары аша җиткереп яшәве хакында әйтте. "Вәлиулла хәзрәтне "идеяләр генераторы" дип атыйлар иде, чыннан да, ул бик күп дини эшләр башлангычында торган имам. Халкыбызның рухи мирасын, дини мәгарифен, бөек галимнәребезнең мирасын белгән һәм аларны халыкка җиткергән хәзрәт. Моны аның чордашлары да, аның белән бергә эшләүчеләр дә яхшы хәтерли. Кызганыч, бүгенге көндә хәзрәт исеме белән уйнаучылар, ягъни үзләрен аның укучылары дип атаучылар да бар. Ниндидер бер галим, остаз турында сөйләгәндә, мин аның укучысы, диючеләр күп булыр, ә остаз аларны үзенең укучысына санаганмы соң?!" - диде Камил хәзрәт Сәмигуллин мөселманнар белән аралашканда.



Шулай ук мөфти җыелган халыкка Вәлиулла хәзрәтнең яңа китабын тәкъдим итте. "Хузур" нәшрият йорты "Иман" нәшрияты белән берлектә танылган дин галиме Вәлиулла хәзрәт Якуповның "Ханафитский мазхаб, его значение и актуальность" дип аталган китабын чыгарды. Мәгълүм булганча, узган ел нәзарәт тарафыннан "Вәлиулла хәзрәт Якупов турында истәлекләр" җыентыгы бастырылган иде. Әлеге китаплар хәзрәтнең каберен зиярәт кылырга җыелган мөселманнарга да таратылды.

Чарада катнашкан Мансур хәзрәт, Җәлил хәзрәт күп еллар дәвамында Вәлиулла хәзрәт белән аралашып яшәүләре, бергәләп дини эшчәнлек алып барулары хакында җылы сүзләр белән искә төшерделәр. Җәлил хәзрәт: "Вәлиулла хәзрәт белән мин аның газета чыгара башлаган яшь егет вакытыннан ук таныш. Ул китап белән яшәде. Бар байлыгы да - җыйган китаплары. Мәрҗанине бик зур хөрмәт белән укый иде. Үзе дә аның кебек хәбәрдар булырга һәм дини хезмәтләрне өйрәнергә омтылды", - диде.

Вәлиулла хәзрәтне искә алып, аның дини эшчәнлеген зурлап сөйләнгән чыгышлардан соң Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Төркиядән килгән коръәнхафизлар Коръән укыдылар. Аннары барлык мөселманнар бергә олуг һәм мәшһүр имам, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якупов рухына багышлап дога кылдылар. Динебезгә һәм милләтебезгә хезмәт иткән Вәлиулла хәзрәтнең рухы шат, урыны җәннәттә булсын! Аның хезмәтләре, игелекле гамәлләре, иншә Аллаһ, Татарстан мөселманнары күңелендә күп еллар дәвамында сакланыр.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА***

# УЛ МИНЕМ ТУРЫДА ИСТӘЛЕК ЯЗАРГА ТИЕШ ИДЕ...

**Тәкъдир бары тик Аллаһка гына билгеле. Мин үзем турында истәлекләрне Вәлиулла хәзрәт язар дип уйлаган идем, ни кызганыч, аның турында миңа язарга туры килде.**

Узган гасырның туксанынчы елларында дини күтәрелеш башланды. Ул вакытта Диния нәзарәте Уфада иде. Ә анда дини мәсьәләләр белән барып кайту җиңел түгел. Мәчетләр төзибез, балалар укытабыз, бернинди дәреслек-материаллар юк. Шушы вакытта "Иман" мәркәзе төзелде дигән хәбәр булды һәм кулга "Иман" газетасы килеп керде. Ул газетада адрес "а/я 65" дип куелган иде. Ә миңа күрешү өчен Винерның йорт (эш) адресы кирәк. Ниһаять, Галимнәр йортында "Иман" мәркәзе ниндидер кичә үткәрде. Мин шунда Винер белән күрешеп, аннан "а/я 65" кайсы урамдагы нинди йорт ул, дип сорадым. Ул рәхәтләнеп көлде дә миңа Җиңү проспектында "снимать" иткән фатирының адресын бирде.

1992 нче елны мин аны мәчет ачарга чакырдым. Ул мәчет ачудан бик тәэсирләнеп: "Минем мәчет ачуда күп тапкырлар булганым бар, ләкин йөзләгән баланың мәчет эчендә чабып йөргәнен күргәнем юк иде. Нинди генә ярдәм кирәк булса да мөрәҗәгать ит", - диде. Мин шуннан соң бер тапкыр Казанга баргач, аның Җиңү проспектындагы яшәү урыныннан 7 арыш капчыгы китап алып чыктым. Без шуның белән 1993 нче елның язында Бөрбаш мәчетендә - 300 бала, 1994 нче елның язында 500 бала арасында Коръән уку конкурсы үткәрдек. Мәрхүм Вәлиулла хәзрәтнең юк урында китаплар бастыра башлавы безгә бик зур ярдәм булды. Ул искиткеч зур эш эшләде. 1992 нче елда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте оешты. Безнең Балтач районы мәхәлләләре Диния нәзарәтенә керергә дип карар кабул итте. Һәм мөфтият белән эшли башладык. Шулвакыт Вәлиулла хәзрәтнең Диния нәзарәте белән каршылыгы чыкты.




Без ул вакытта да аның белән аралашуны туктатмадык. Мин аны тәнкыйтьләп тә ала идем, ул елмаеп: "Җәлил абый (ул мине яратып гел шулай дип йөртте), без синең белән баррикаданың ике ягында булсак та, арада аңлашылмаучанлык чыкмый. Син мине ничек кенә тәнкыйтьләсәң дә, сиңа ачу да чыкмый. Күп вакыт синең белән килешәсе килми, әмма, ни сәбәптәндер, син хаклы булып чыгасың", - ди торган иде.

1998 нче елны Берләшү съездыннан соң ул мөфти Госман хәзрәт Исхакыйның беренче урынбасары булып сайланды. Аннан соң аралашу тагын да тирәнәйде. Мәчетләрдә, районнарда нинди генә мәсьәләләр килеп чыкса да, без Вәлиулла хәзрәткә мөрәҗәгать итә торган идек. Бар яктан да бик грамоталы кеше иде. Аның белән бик күп җирләргә сәфәр чыгу насыйп булды. Ул кая гына барса да, гел китап җыя иде. Музыка тыңлауны вакытны бушка уздыру дип санады. Эш машинасында магнитофон юк иде. Бик күп укый иде, дини мәсьәләләрдә искиткеч мәгълүматлы, бик күп белә иде. Минем вәгазьләрне халыкка җиткерү өчен бик күп көч куйды, китапларымны чыгарырга ярдәм итте. Вафатына бер көн кала (мин Башкортстаннан кайтып килә идем) ул миңа шалтырата: "Җәлил абый, "Йөз дә бер вәгазь"еңне кабат чыгарырга кирәк, 50 мең сум акча әзерләп куйдым, кемгә бирим?" - дип өзгәләнеп, кат-кат әйтте. Мин: "Вәлиулла хәзрәт, ник бәргәләнәсең, мин бер Казанга килермен, алырмын, борчылма", - дидем. Бу безнең аның белән соңгы сөйләшүебез булды. Ә кем уйлаган соңгысы булыр дип!? Икенче көнне аның фаҗигале үлеме турында хәбәр килде.

Мин аңа бервакыт мөрәҗәгать итеп: "Китапларны бик күп бастырасың, сиңа Аллаһның рәхмәте булсын, әмма бик сыйфатсыз бит, хәрефе вак, кәгазе начар", - дигәч ул: "Минем максат - иске имляда халык укый алмаган китапларны күбрәк кешеләргә җиткерергә һәм китап бастырырга акчасы булмаган кешеләрнең китапларын халыкка җиткерергә. Вакытлар үтәр, кемнәрдер кайсыдыр китапны ошата икән, аннары матур тышлык, сыйфатлы кәгазь белән бастырып чыгарыр", - диде. Безнең район мәктәпләрендә укытыла торган әдәп-әхлак дәресләренә бик сөенеп карый иде ул, әхлак укытучыларының республика методик советын төзергә теләде. Аның шул юнәлештә зур семинар үткәрәсе килде, әмма кемнәрдер каршы төшеп, үткәрергә ирек бирмәделәр. Әгәр үз вакытында шушы эш барып чыккан булса, мәктәпләрдә укытыла торган ислам культурасына зур әзерлек белән килә идек.

Ул галимнәр белән дин әһелләре арасында күпер булдыруга зур көч куйды. Апанай мәчетен нинди матур итеп аякка бастырды. Мәчете төзекләндерелеп ачылганнан соң, беренче җомганы миңа үткәрергә туры килде. Җомгадан соң: "Җәлил абый, Аллаһы Тәгалә догамны кабул итте, беренче җомганы синнән укытасы килгән иде", - дип сөенечен белдерде. Әлбәттә, кайвакыт фикерләре дә үзгәреп куя иде. Аны кайбер кешеләр: "Син элек бер фикердә идең, хәзер башкада", - дип тәнкыйтьләде. Ул елмаеп: "Мин тәүбәгә килеп, фикеремне үзгәртә алганмын икән, бүтәннәргә нәрсә комачаулый?" - дия иде.

... Җиденче сыйныфта укыганда минем кулыма "Мең дә бер кичә"нең кайсыдыр бер кисәге килеп керде. Ул том минем динилегемне бик нык арттырган кебек булды. Герой кыен ситуациядә гел Аллаһы Тәгаләгә ялвара. Бервакыт поездда барганда Вәлиулла хәзрәт: "Җәлил абый, беләсеңме, миңа мәктәптә укыганда "Мең дә бер кичә" китабын укырга туры килде, мин хәтта әкият геройлары кылган догаларны бер дәфтәргә язып алдым", - диде. Мин шулхәтле гаҗәпләндем, Вәлиулла хәзрәт белән безгә бер үк китап тәэсир ясаган икән, мин бу турыда кешегә әйтергә кыенсынып йөри идем.

Вәлиулла Якуп - динебезне үстерүгә һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлеген алып баруга үзеннән зур өлеш керткән шәхес. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең эшчәнлеген дә ул башлап җибәрде. Тарих аның хезмәтләренә алга таба бәясен бирер. Әйткән сүзләребез аның рухына дога булып барып ирешсә иде. Әмин!

***Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,***
***Татарстанның баш казые***
***("Вәлиулла хәзрәт Якупов турында истәлекләр" китабыннан)***

# АЛМАГАЧНЫҢ АЛМАСЫ...

**Риваятьләрдә Әбү Хәнифәнең әтиәнисе күркәм холыклы кешеләр итеп тасвирлана. Аларның танышулары турында менә мондый риваять бар.**

Әбү Хәнифәнең әтисе Сабит егет чагында, нәкъ яшьлегенең таңында бер агымсу читендә тәһарәт ала. Тәһарәтен тәмамлап, догалар укып сөртенгәч, су агымына күз сала һәм күрә - су өстендә аклы-кызыллы чуар бер алма йөзеп килә. Алманың су өстендә уйнап, балкып йөзүе Сабитның күңелен хушландыра һәм ул алманы үрелеп алып тешли. Алманы тешләп, аның тәмен тою белән сискәнеп китә: тукта, мин нишләдем! Бу алманың хуҗасы бардыр бит. Үземнеке булмаган әйберне алдым да хуҗасының рөхсәтеннән башка тешләдем...

Ул аң йокысыннан кинәт уяна һәм су агып килгән якка китә. Бераз баргач, су өстенә иелгән агачларны күрә. Кулындагы тешләнгән алманы карый: ул агачтагы алмаларга охшаган була. Димәк, мин тешләгән алма шушы бакчаныкы икән, дип ул бакча хуҗасын эзләп таба. Үзара сәламләшкәннән соң: "Әфәндем, бу сезнең агачлардан төшкән алма булырга охшап тора. Мин тәһарәт алганда ул су белән агып килә иде. Мин аны уйламыйча гына алып тешләдем. Шунда гына аңыма килдем, гафләттә (уяусызлыкта) булганымны аңладым. Бу алманың хуҗасы бардыр, аны табып, хәләллеген сорыйм, алманың баясен түлим, дип сезгә килдем. Инде сездән ризалык сорыйм, алмагызның хакын түлим. Сезнең рөхсәттән башка алмагызга кагылган өчен мине гафу итегез, хатамны кичерегез, - дип үтенә, ялвара башлый.

Бакча хуҗасы:

- Юк, гафу итмим... Ни өчен син аны минем рөхсәтем, ризалыгымнан башка тешләдең? - ди.

Әбү Хәнифәнең әтисе:

- Ярар, әфәндем, мин бурычлы. Алма өчен ни сорасагыз да бирергә әзермен. Әйтегез! - дип үтенә.

Бакча хуҗасы:

- Миңа өч ел хезмәт итәрсең, минем белән эшләрсең, соңыннан уйлашырбыз. Сиңа котылу чарасы менә шул, - ди.

- Ярар! - ди Сабит. Бер мизгел аңсызлык, гафләт өчен, кыскасы, бер алма өчен өч ел хезмәт итәчәк!.. Әмма башка котылу юлы юк. Буласы булган - алманың суы авызына кергән. Аны хәләл итү лазем. Моны бары тик мал хуҗасы гына эшли ала. Ул бит әле өч ел хезмәт иткәннән соң да гафу итүне шарт итте, уйларбыз, диде.

Имам Әбү Хәнифәнең әтисе - хәзрәти Сабит өч ел шушы бакчада чиләнде. Соңгы көннәрендә бигрәк өзгәләнде, шушы өч елымны тутырып өемә кайтсам иде, диде. Өч ел тулган көнне хуҗа янына барып:

- Әфәндем. Бүген соңгы көнем - өч ел тулды. Хакыгызны хәләл итсәгез, мин китәр идем, - диде. Бакча хуҗасы:

- Мин хакымны бары тик бер шарт белән генә хәләл итәм. Без бит өч ел үткәч уйлашырбыз дип килештек. Мин уйладым. Бер зур шартым бар, аны да үтәсәң, хакымны хәләл итәрмен. Минем бер кызым бар. Күзләре күрми, колаклары ишетми, куллары тотмый, аяклары юк. Менә шул кызыма өйләнеп, никахлап алсаң, мин сине гафу итәм, хәләллим. Башкача гөнаһыңны кичерү юк, - ди.

- Ярар, - ди хәзрәти Сабит чарасыздан.

Туй хәзерлекләре күрелә, сый мәҗлесе әзерләнә, никах укыла. Кияү керү мизгеле җитә... Керә һәм күрә. Каршында саусәламәт, камил, кояш кебек гүзәл кәләш! Монда ниндидер ялгышлык бар, дип уйлап, ул тиз генә каенатасы янына бара.

- Әфәндем, сез миңа: "Кызым - күзсез, колаксыз, кулсыз, аяксыз", - дидегез. Ә мин саусәламәт бер дөнья гүзәле белән кавыштым. Моны ничек аңларга? - ди ул аптырап.



Тегесе аңа:

- Әйе, балам, минем кызым бик динле. Хәрәмгә бакмас - димәк, күзсез; хәрәм сүзләргә колак салмас - димәк, чукрак; кулына хәрәм әйбер алмас - димәк, кулсыз; хәрәм җирләргә йөрмәс - димәк, аяксыз. - Мин әнә шуларны күздә тоткан идем. Кызыма синең кебек иман әһеле эзләдем. Калебендә Аллаһтан куркү хисе булсын, үзен хәрәмнәрдән сакласын, Аллаһ тыйган нәрсәләрдән ерак торсын, кызыма һәм аннан туачак оныкларыма хәрәм ашатмасын, дидем. Хакхокукны күрә, аера белә торган камил иманлы кияү булсын, дидем. Менә Аллаһ уйламаганда миңа сине күндерде. Син бер алманың хәләллеген үтенеп килгәч, күңелең тулы җәүһәр, вөҗданлы кеше икәнеңне аңладым. Әмма сиңа имтихан тоту кирәк иде. Озын-озак өч ел буе үзеңне сынадым. Һәр хәлеңне, һәр хәрәкәтеңне күзәттем. Мин көткән бөтен сыйфатлар синдә бар. Шуның өчен йөрәк парәм булган бердәнбер кызымны әманәт иттем. Шатланышып, бәхетле булып, бер ястыкта картаегыз, ди.

Имам Әбү Хәнифә әнә шундый әнидән һәм әтидән туган.

*"Шура" (№1) альманахыннан*

---

## РАМАЗАНДА ЯКЫНЛЫК КЫЛЫРГА ЯРЫЙМЫ?

**СОРАУ:** ***Рамазан аенда кояш баеганнан алып таң атканчыга кадәр хәләл җефетең белән якынлык кылырга ярыймы?***



**ҖАВАП:** Ибне Касир тәфсирендә болай диелә: "Ибне Җәрир әйткән: "Рамазан аенда ураза тоткан кешеләргә кояш баеганнан соң йокларга ятсалар, ашау, эчү һәм якынлык кылу киләсе ифтарга кадәр хәрәм була".

Бервакыт Гомәр ибне Әл-Хаттаб (р.г.) Пәйгамбәребез (с.г.в.) белән соңга кадәр сөйләшеп утыра һәм өенә төнлә кайтып керә. Хатынын йоклаган килеш күрә һәм теләге уяна. Хатыны аңа: "Мин йоклаган идем", - дип әйтә. Ләкин Гомәр (р.г.): "Син йокламаган идең", - дип җавап кайтара һәм хатыны белән якынлык кыла. Ибне Мәлик тә шулай эшли. Икенче көнне Гомәр Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына килә дә, барысын да сөйләп бирә. Һәм Аллаһы Тәгалә тән дәвамында ашау, эчү һәм якынлык кылуны рөхсәт итә торган "Бәкара" сүрәсенең 187 нче аятен иңдерә.

## "СӨЕНЧЕ, СИНЕҢ КЫЗЫҢ ТУДЫ!"

**Бала - Аллаһның безгә биргән иң зур бүләге, нигъмәте. Әмма кайбер кешеләр сау-сәламәт бала туганга канәгатьләнәсе урында, мин бит Аллаһтан угыл сораган идем, ул миңа кыз бала бирде, дип ризасызлык белдерәләр. Димәк, бу кешеләр Аллаһ тәкъдиренә каршы килә булып чыга. Кыз баласы туганга улы туганга сөенгән кебек сөенү ата-ананың иң мөкатдәс хисе һәм бурычы булырга тиеш. Чөнки кемгә ир бала, ә кемгә кыз бала бирүне бары Аллаһы Тәгалә генә хәл итә. Кеше Ул биргәнгә рәхмәтле булырга, Ул биргәнне аның нигъмәте итеп кабул итәргә тиеш. Изге Коръән безне шуңа өйрәтә.**

Җәһилият чорында йөкле хатын-кызлар кем туасы билгеле булганчы кешедән качып йөргәннәр. Ир бала туса, алар моны кешеләргә шатланып хәбәр иткән, кыз баласы туса, кара кайгыга баткан. Кайбер кабиләләрдә фәрештәләр Аллаһның кызлары булып исәпләнгән, хатын-кызларны да фәрештәләр дип атаганнар. Кыз бала тугач, алар: "Кызлар кызлар янына китсен", - дип, сабыйларын тереләй күмгәннәр, таш кыядан ташлаганнар, суга батырганнар. Мондый мөнәсәбәт фәкыйрьлектән һәм кыз бала үскәч, аларны оятлы итә торган гамәлләр кылыр; сугышлар чыгып, аларны коллыкта сатарлар, дип куркудан килеп чыккан булса кирәк. Бу хакта "Нәхел (Умарта кортлары)" сүрәсендә болай диелгән: "Дәхи Аллаһның кызлары бар, дип ифтира кылалар, мондый кимчелектән Аллаһны пакь дип белегез! Алар фикеренчә, үзләре сөйгән ир балалар аларга була, әмма алар сөймәгән кыз балалар Аллаһка була, имеш. Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә кыз балаң туган, дип сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып, йөзе каралып китәдер. Кыз белән сөенеч бирелгәнлектән хурланып кавеменнән качадыр, уйлап торадыр: бу кызны хурланып кына асрыйм микән, яки тереләтә туфракка күмеп таптыйм микән, дип. Әгаһ булсыннар, кылган эшләре нинди яман кабахәт эштер!" (57,58,59 нчы аятьләр).

Ислам дине таралгач, кыз балаларга мөнәсәбәт тамырдан үзгәргән. Исламда ата-ана кыз баланы күз карасы кебек саклап тәрбияләргә, аның бәхете өчен зур җаваплылык хисе тоярга, балигъ булгач, иманлы хәерле кешегә никахлап кияүгә бирүне кайгыртырга тиеш.

Ә кыз баланы тәрбияле тәкъва итеп үстерүнең әҗеренә килгәндә исә аны санап бетергесез, бу хакта бик күп хәдисләр бар. Әнәс ибне Мәлик (радыйаллаһу ганһү) тапшыруынча, Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Кем ике кыз баланы балигълыкка җиткәнче үстерә, шул кеше Кыямәт көнендә минем белән янәшә барыр", - дигән һәм ике бармагын бергә куйган.

### ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

Балага куша торган исемнәрнең кайберләре хәрәм булып санала. Шуларның берсе - Аллаһы Тәгалә исемнәре. Аның исемнәре бик күп, безгә билгеле булганнары 99. Әгәр кеше ялгыш Аллаһ исемен кушса, тәүбә кыла, башка хәләл булган исемгә



алыштыра. Әгәр алыштырмаса, олы гөнаһлы була һәм аның өчен аңа дөньяда да газап, тәүбә кылмыйча үлеп китсә, җәһәннәм газабы була. Балаларыбызга, хәрәмгә керешмичә генә, күркәм исемнәр сайлыйк.

Ир-ат исемнәре

Алдан (борынгы төрки-татар) - гаиләдә беренче булып туган
Аллаһияр (гарәп-фарсы) - Аллаһ дусты
Алмаз (г.-грек) - асылташ
Алмас (бор.төр.-т; йола исем) - яман көчләр бу баланы алмас
Алмаш (бор.төр.-т.) - алмашка килүче
Аманулла (г.) - Аллаһның сау-сәламәт кешесе
Ансар (г.) - ярдәмчеләр
Апанай (бор.төр.-т.) - аба-апа (өлкән туган) сүзенә - най кушымчасы ялганып ясалган
Арслан (төр.-т.) - арыслан
Аршак (бор.иран) кыю, гайрәтле ир

Хатын-кыз исемнәре

Алтаң (т.; неологизм) - таң кебек алсу
Алтынчәч (бол.-т.) - алтын төсле сары чәчле
Алчәчәк (т.; неол.) - ал чәчәк кебек
Ансария (г.) - ярдәмчеләр
Анфиса (Әнфисә) (гр.; неол.) - чәчәк атучы
Асия (г.) - тынычландыручы, дәвалаучы, юатучы
Аслия (г.) - төп, асыл, чын
Асыл (г.) - иң затлы
Асылъяр (г.-ф.) - асыл яр (дус, иптәш)
Афтаб (ф.) кояш кебек матур кыз бала

***Гомәр Саттарның "Исемең матур, кемнәр куйган?" китабыннан***

## Коръәнхафиз ГОМӘР КҮЧҮКБАЛТАДҖЫ:

# "КАЗАННЫ КАРАРГА МАХСУС КИЛӘМ ӘЛЕ"

**Рамазан аенда Татарстан Республикасына Төркиядән 29 коръәнхафиз килеп төште. Алар Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте белән Төркиянең Ислам эшләре һәм вәкыф министрлыгы арасындагы хезмәттәшлек программасы кысаларында чакырулы иде. Коръәнхафизлар рамазан ае дәвамында Татарстан шәһәрләре һәм авыллары мәчетләрендә Коръән хатем чыгалар, тәравих намазлары укыйлар, җирлектәге имамнарга ярдәм итәләр.**



Казанның Гаилә мәчетендә тукталган 29 яшьлек коръәнхафиз Гомәр Күчүкбалтаджы - Истанбул егете. Коръәнне Истанбулның Эренкей Коръән курсларында өйрәнгән, Сакарйя университетының илаһият факультетын тәмамлаган. Хәзер инде Кадыкей районындагы мәчеттә имам-хатыйблык вазифаларын башкара икән.

- Чит илгә чыгып эшләү теләге күптән бар иде. Танышларым узган ел ук Европа, Азия илләрендә булып кайтты, - дип сөйли Гомәр бу якларга ничек килеп чыгуы турында сорашкач. - Дөресен әйтим, мин Татарстанны үзем сайлап алмадым, без кая барасыбызны алдан белми идек. Чит илгә чыгып эшләр өчен теләк белдереп, башта гариза яздык, аннары имтихан тоттык.

Мин әти-әнием белән яшим. Россиягә барыр өчен аларның ризалыгын алу шактый авыр булды. Ә үзем Татарстанга барасымны белгәч, бик сөендем. Россиядә безгә кардәш халыклар яшәве турында тарихтан укып белә идем. Үземне чит итеп хис итмәм дип уйладым, чөнки без бит - төрки халыклар, ә иң мөһиме - мөселманнар. Казанда мөселманнар бик күп икән, мөселман дәүләтенә эләккәндәй булдым...

***- Димәк, Татарстан Сезгә ошады?***

- Әйе, Татарстанны да, Казанны да бик ошаттым. Халкы, кешеләрнең үзара мөнәсәбәте бик җылы тәэсирләр калдырды. Тәравих намазларына да бик күп кеше йөри. Дөрес, Казанны йөреп чыга алмадым әле. Ике тапкыр Колшәриф мәчетендә һәм Россия Ислам институтында булдым. Күбрәк мәчеттә утырам. Гаилә мәхәлләсендә мине бик җылы каршы алдылар, барлык хәзрәтләр дә игътибарлылар, ярдәмчел кешеләр. Монда килеп төшкәч, биек-биек йортларда яшәүчеләрнең мәхәлләгә берләшүләрен күреп, башта аптырабрак калдым, мәхәллә системасы бездә башкачарак ул...

***- Коръәнхафиз буларак, башка мөселман дәүләтләрендә эшләргә туры килгәне бармы?***

- Юк, Татарстан минем беренче тәҗрибәм. Ә болай мөселман илләренә күп йөрим. Косовода, Сүрия, Согуд Гарәбстанында булганым бар. Күргәннәрем буенча шундый нәтиҗәгә киләм: мөселман дөньясы бөтен җирдә дә бертөрле. Кызганычка, ислам культурасы әле көчле үсеш алмаган. Мәккә-Мәдинәдә дә, бездә дә, сездә дә шул ук хәл - Европа мәдәнияте белән яшибез, яшәү рәвешебез европача, биналарыбыз да, юлларыбыз да, кигән киемнәребез, ашаган ризыкларыбыз да, хәтта дөньяга карашыбыз да Европа кешеләренекеннән аерылмый. Менә шул уйлар миңа тынгы бирми.

***- Ислам юлыннан кереп китүегезгә әллә шул сәбәпче булдымы?***

- Бу - тәкъдир. Коръәнхафиз булып китүемне мин Аллаһы Тәгаләнең бер рәхмәте дип кабул итәм. 12 яшемдә лицейга кергәндә мин имтиханнарымны бирә алмадым. Һәм вакытны бушка уздырмас өчен генә Коръән ятлау курсларына язылдым. Ничек дөрес эшләгәнмен мин ул чакта! Тормышымның иң яхшы, иң файдалы чоры булды ул өч ел. Әти-әнием дә бик сөенеп фатиха бирделәр. Әтием үзе дә, өч сеңелем дә илаһият белгечләре минем. Кечкенә генә бер этәргеч кеше язмышына нинди зур тәэсир ясый ала. Исламны, хак юлны табуда кешеләргә әнә шул этәргеч көчне бирә алсак иде.

Без үз мәхәлләбездә студентлар өчен тулай торак кебек йортлар ачтык. Шунда алар белән ислам турында сөйләшәбез, теләк белдергәннәрен Коръән укырга өйрәтәбез.

***- Татарстанда андый курслар һәр мәчет каршында оештырылган...***

- Безнең мәчетләрдә дә бар андый курслар, аларда динебезгә кагылышлы бөтен нәрсәне өйрәтәбез. Төрле яшьтәге кешеләрне укытабыз: яшьләрне дә, өлкәннәрне дә. Ләкин бу - рәсми булмаган курслар. Истанбулның үзендә, мәчетләрдән тыш, күп җирләрдә Коръән курслары эшләп тора.

***- Игътибар иткәнсездер инде, мәчеттә һәр көнне 250-300 кеше өчен ифтар ашлары әзерләнә. Бу әле соңгы елларда гына киң таралыш алды. Сездә дә андый ифтар мәҗлесләре оештырыламы?***

- Гадәттә ифтар ашлары гаиләдә, туганнар, күршеләр арасында үткәрелә. Андый мәҗлесләрдә бик җылы атмосфера була, туганнар белән тагын да якынаясың. Ләкин соңгы арада бездә дә шушындый ифтарлар модага керә башлады - бер кеше, бөтен чыгымнарын үз өстенә алып, мәчеттә 200-300 кешелек ифтар ашлары уздыра. Мин моныcын да хуплыйм. Таныш булмаган чит кешеләр бер табын артына җыелып, якынаеп, дуслашып китә. Кайвакытта мәҗлесләргә мөселман булмаган кешеләр дә килә. Бу бик яхшы күренеш: күрсеннәр алар да мөселманнарның ничек яшәгәннәрен.



*Соңгы арада бездә дә шушындый ифтарлар модага керә башлады - бер кеше, бөтен чыгымнарын үз өстенә алып, мәчеттә 200-300 кешелек ифтар ашлары уздыра. Мин моны хуплыйм. Таныш булмаган чит кешеләр бер табын артына җыелып, якынаеп, дуслашып китә. Кайвакытта мәҗлесләргә мөселман булмаган кешеләр дә килә. Бу бик яхшы күренеш: күрсеннәр алар да мөселманнарның ничек яшәгәннәрен.*

***- Бу сорауны кыенсынып кына бирәм: чит җирдә берьялгызыгыз, җитмәсә, мәчеттән дә сирәк кенә чыгасыз, авыр түгелме? Вакытыгызны ничек уздырасыз?***

- Никадәр генә яхшы коръәнхафиз булсаң да, бөтен Коръәнне хәтереңдә тоту бик авыр. Шуңа күрә даими төстә шөгыльләнергә кирәк. Минем һәр минутым бүленгән. Мәхәллә халкы алдында оятлы булыр хәлем юк, кыскасы, көне буе укыйм. Шуннан башка бернигә дә вакыт калмый. Казанны бер йөреп чыгасы килә килүен, әмма вакыт юк. Мин бит монда эшләргә дип килдем, дәүләтемнең дә ышанычын акларга кирәк. Төркиянең бу миссиясе миңа бик ошый, илләребез арасында яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыру, бер-беребезгә ярдәм итү өчен дә кирәк бит ул. Иң беренче чиратта - Аллаһы ризалыгын өмет итеп, мондагы мөселманнар белән аралашу өчен килдек без. Ә Казанны карарга рамазаннан соң килермен әле, Иншә Аллаһ.

***Әңгәмәдәш – Айзилә КӘБИР***



# "ХУЗУР" ЯҢА КИТАПЛАР ТӘКЪДИМ ИТӘ

**Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның рамазан аенда чыккан "Ураза" китабы мөселманнар өчен зур бүләк булды. Бу китапка танылган авторлар тарафыннан язылган дини тәгълиматлардан, башка китаплардан өзекләр дә кертелгән. Биредә ураза төрләре, аны тоту кагыйдәләре, аның әҗере турында мәгълүмат урын алган. Һәр хәдисне кайсы китапта табып булу турында искәрмә бар. Китап гади тел белән язылган, дини лексика, катлаулы терминология кулланылмаган.**









Тарих белән кызыксынучылар өчен "Хузур" нәшрият йорты "Путешествие Ахмеда ибн-Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии ислама" дигән китап бастырып чыгарды. Әлеге китап Әхмәд ибне-Фадланның мәшһүр юлъязмалары буенча язылган. Анда Багдад хәлифәте илчесенең Идел буена сәяхәте, Көнчыгыш Европадагы зур вакыйга - 922 нче елда Идел буе Болгар дәүләтенең ислам динен рәсми төстә кабул итүе тасвирлана.

Ислам дине тәгълиматчысы, җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты Вәлиулла Ягъкупның (1963-2012) "Ханафитский мазхаб, его значение и актуальность" дигән китабында хәнәфи мәзһәбенең әһәмияте, актуальлеге күрсәтелә. "Хузур" нәшрият йорты "Иман" нәшрияты белән берлектә Дини гореф-гадәтләрне торгызу елы кысаларында әлеге китапны кабат бастырып чыгарды. Китапка шулай ук имам Әбү Хәнифәнең "Аль-Фикх аль-Акбар" дигән әсәре дә кертелгән.




Республика имамнарына атап әзерләнгән "Шура" журналының да бишенче саны дөнья күрде. Бу сан, нигездә, мөбарәк рамазан аена багышлана. Рамазан ае өчен махсус вәгазьләр, Ураза гаете хөтбәсе бирелгән. Шулай ук рамазан аеның фазыйләтләре, рамазан хакында хәдисләр, ураза тотуга кагылышлы мәкаләләр урнаштырылган. Анда Татарстан мөфтие Камил хәзрәтнең татар имамнары форумында ясаган чыгышы һәм динебез үзенчәлекләрен аңлаткан вәгазьләре белән дә танышырга мөмкин. Нурислам хәзрәт Ибраһимов, Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Ришат хәзрәт Курамшин, нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге белгечләре әзерләгән эчтәлекле вәгазьләр халкыбызга ислам кыйммәтләрен җиткерә. Альманахта күп сандагы дини сорауларга җаваплар да урын алган.

"Шура" альманахының бишенче саны бай рухи мирасыбызны яктыртуны дәвам итә. Әйтик, Ризаэддин Фәхретдиннең инкыйлабка кадәр - 1913 нче елда "Шура"да басылган "Мәшһүр адәмнәр вә олуг хәдисәләр. Фөзули" мәкаләсе белән бүгенге заман укучылары да таныша ала. Журналда мөселман уку йортларына кагылышлы мәгълүматлар, намаз вакытлары, көн дә укый торган догалар урын алган.

"Шура" альманахы Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөхәррирлегендә кварталга бер тапкыр нәшер ителә. Альманах республиканың барлык имамнарына бушлай таратыла.

***"Хузур" нәшрият йортының сайты - huzur.ru.***

***Казандагы кибетләре адреслары: Лобачевский урамы, 6 нчы йорт һәм Газовая урамы, 19 нчы йорт.***

***Заказ бирү өчен телефоннар: (8843) 2-02-07-74; 8 (965) 596 5537***







## КАЗАН ТӘМЛЕТАМАКЛАРЫНА ГАРӘП КҮЧТӘНӘЧЕ

*BATEEL бутигы - хөрмәнең 20 сорты; шоколадлы, цукат һәм чикләвекле хөрмәләр; табигый шоколад; Италиядә җитештерелгән зәйтүн мае; Согуд Гарәбстаныннан китерелгән гарәп каһвәсе.*

*BATEEL, югары сыйфатлы хөрмә бренды булудан башлап, затлы азык-төлекләр базарында иң данлыклы маркага әверелде. Дөньяның уналты илендә уңыш казанган зиннәтле BATEEL бутиклары, кафелары Лондоннан алып Джакартага кадәрле бик күп мегаполисларның эре сәүдә үзәкләрен бизи.*

*BATEEL бутигында продуктларның искитмәле тәменнән башлап бизәк төшерелгән поднос рәвешендәге оформлениегә кадәр бар да купшы һәм кабатланмас - сатып алучылар үзләрен нәкъ көнчыгыш әкиятендәгедәй хис итәр.*

*Аллаһ Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәлам) болай дигән: "Хөрмә оҗмах җимеше. Ул агуланудан дәвалау үзлегенә ия" (Тирмизи: Тыбб, 22).*

*BATEEL брендын чын тәмлетамаклар сайлый.*











ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27) .*
**Нәшир: "Хузур" нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

**Июль саны, № 7 (228)**

**Баш мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН;***
*"Хузур" нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН;***
*Татарстан мөфтие урынбасары* ***Нияз САБИРОВ;***
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ;***
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ.***

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09613
**Тираж: 10 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **21 нче апрель көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru**
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!**